# РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАРГА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ НИГЕЗЕНДӘ УКЫТУ ПРОГРАММАСЫ

*1—11 нче сыйныфлар*

**Төзүче-авторлары:**

***Р. З. Хәйдәрова,***
педагогика фәннәре кандидаты, доцент

***Р. Л. Малафеева,***
югары категорияле методист

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

1992 нче елның 8 нче июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Татарстан Республикасы Законы нигезендә татар һәм рус телләре тигез хокуклы дәүләт телләре булып расланды. Мәгариф министрлыгы җитәкчелегендә бик кыска вакыт эчендә нәтиҗәле эш оештырылды: рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укытуны оештыру буенча махсус программалар, дәреслекләр, методик әсбаплар, дидактик материаллар әзерләнде, бу юнәлештә билгеле бер тәҗрибә тупланды, психологик, педагогик нәтиҗәләр ясалды. Бүгенге социолингвистик ситуациядә һәм гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандартлары тормышка ашу кысаларында рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәтү буенча яңа программалар эшләү зарурлыгы килеп басты.

Тәкъдим ителгән программа психология, педагогика фәннәренең яңа казанышларына таянып һәм тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология нигезендә укыту принципларын исәпкә алып төзелде.

Программа аңлатма язуыннан һәм төп өлештән тора. Программаның аңлатма язуында татар теле укытуның максатлары, программа эчтәлеген сайлауның төп принциплары, гомуми урта белем бирү мәктәбенең һәр баскычында сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча укучыларның нинди белем күнекмәләренә ия булырга тиешлеге күрсәтелде. Төп өлештә һәр сыйныфта татар теле өйрәнүнең тематик эчтәлеге, лингвистик материал күләме, аларның укыту сәгатьләренә бүленеше, белем һәм күнекмәләрне бәяләү нормалары күрсәтелде.

Һәр баланың үзләштерү мөмкинлеге аның табигый индивидуаль үзенчәлегенә нигезләнгән. Программа һәм дәреслек материалын барлык балаларның да бердәй үзләштерүе мөмкин түгел һәм моны таләп итәргә ярамый. Үзләштерү сыйныфтан сыйныфка ныгый бара. Шуңа күрә программага һәм дәреслеккә материал тематик-концентрик принципка (бер үк темаларның сыйныфтан сыйныфка киңәйтелеп кабатланышы) нигезләп тупланды. Алдагы сыйныфлардагы материалны кабатлау дәреслек эчтәлегендә оештырылу мөмкинлеген истә тотып, программада һәр сыйныф буенча, нигездә, яңа лингвистик материал һәм сөйләм үрнәкләре генә күрсәтелде.

## РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАРГА ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ

Билгеле булганча, укытуның максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы — иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт телендә һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы билингваль (полилингваль) шәхес тәрбияләү.

Рус телле балаларга татар теле укыту максаты күпкырлы, һәм ул берничә аспекттан тора: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

### 1. Танып белү максатының эчтәлеге

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен «башка дөньяга тәрәзә ачу» (И.Л.Бим) булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Татар исемнәрен, Татарстанның табигатен, җирлеген, топонимикасын дөрес әйтә белергә өйрәтү, аларның семантикасы белән кызыксындыру, балалар фольклоры, татар халык авыз иҗаты, әдәбият-сәнгать вәкилләре белән беренчел таныштыру **башлангыч этапта** танып белү максатының төп эчтәлеген тәшкил итә. **Урта звенода** Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстан символикасы, башкалабыз Казанның тарихы, бүгенге йөзе, Татарстанның территориясе, географик урыны, экономик бәйләнешләре, татар сәнгатенең төрле тармаклары буенча билгеле булган шәхесләр, Бөек Җиңүгә Татарстанның өлеше турында укучыларның татарча сөйли алулары төп максат итеп куелды.

**Югары сыйныф** укучылары, нигездә, 1—9 нчы сыйныфта алган белемнәрен киңәйтәләр, тулыландыралар. Аларның алда аталган темалар һәм Татарстанның югары уку йортлары, яңа экономик үсеш дәрәҗәсе, дөньякүләм аренада бүгенге урыны, бөтендөнья спорт үсешенә керткән өлеше, Татарстандагы яшьләр хәрәкәтләре турында иркен аралашуга чыгулары максат итеп куела.

### 2. Үстерү максатының эчтәлеге

Белем бирү максаты методика фәнендә бик озак еллар буе беренчел дәрәҗәдәге максат итеп саналды. Ләкин дидактик максатларның башкаларын икенчел дәрәҗәдә дип карау, киресенчә, белем бирү максатының тиешле дәрәҗәдә тормышка ашырылмавына китерде. Шәхеснең белемле булуы тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында үстерү, тәрбия максатларын даими күзаллап эшләү — укытуның практик ягы уңышлылыгының

алшарты (Л.С.Выготский). Бу хакыйкатьне балаларның белем алу эшчәнлегенең барлык этапларында да истә тоту зарур.

Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар таләп ителә:

— фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;

— хәтерне үстерү (ихтыяри, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;

— аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисселек, эмпатия хисләре);

— ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне үстерү.

Программага сайланган эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда, бу максатлар беренче планга куела.

### 3. Тәрбияви максатның эчтәлеге

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Әлбәттә, укытучының шәхси сыйфатлары, укучы белән махсус оештырылган мөгамәләсе укыту-тәрбия процессында зур роль уйный. Ләкин тәрбия процессы беренче чиратта укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алу авторларның беренчел бурычы булды. Балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән, аларны кызыксындырган мораль проблемаларны үз эченә алган эчтәлек, беренчедән, укыту процессында тәрбияви функция башкарса, икенчедән, турыдан-туры коммуникатив мотивация туу белән бәйле.

Уку эшчәнлеген мотивлаштыру юнәлешендә эшләүче галимә А. К. Маркова фикеренчә, эчтәлегендә әхлакый проблемалар булган текстлар үзләре үк коммуникатив мотивациягә ия, шунлыктан аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый. Башка милләт вәкилләренең күңелен яулардай, аларда гомумкешелек әхлакый сыйфатларны тәрбияләрдәй татар әдәбияты өлгеләре белән таныштыру да шушы ук максатка буйсындырылды һәм сөйләшү-аралашуга алып чыгуга кулайрак булган әдәби әсәрләрнең авторлары тәкъдим ителде. Программаның ачык характерда булырга тиешлеген исәпкә алып, әдәби әсәрләр үзләре күрсәтелмәде, ә авторларны санап чыгу белән чикләнелде.

Укучыларның кабул итү мөмкинлекләрен исәпкә алып, аралашу-сөйләшү проблемаларына туры килгән әдәби әсәрләрдән төрле өзекләр сайлауны дәреслек авторларына калдыру методика фәнендә программага эчтәлек сайлауда монополиялектән котылуның бер юлы дип күрсәтелә.

### 4. Белем бирү максатының эчтәлеге

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм

эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни укучылар нинди дә булса сүзне я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатында мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

Гомуми урта белем бирү мәктәбен тәмамлаганда, укучының **сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белемнәргә ия булуы** күздә тотыла.

### БАШЛАНГЫЧ ЭТАП

#### Тыңлап аңлау

Укытучының дәрес, уен ситуацияләре белән бәйле сорауларын, күрсәтмәләрен аңлау;

тыңлаганда, җөмлә, сүз чикләрен билгеләү, интонацияне аеру;

сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны берберсеннән ишетеп аера белү;

сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итә белү;

ишеткән сөйләмнең, җөмләнең эчтәлегенә төшенү.

#### Диалогик сөйләм

Өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;

программада күрсәтелгән темалар буенча укытучының сорауларына җавап бирү һәм сораулар куя белү;

дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

#### Монологик сөйләм

Җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;

тәкъдим ителгән план, терәк сүзләр ярдәмендә укылган өзек яисә караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү;

укыган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү;

үзе, гаиләсе һәм дуслары турында кечкенә информация бирә белү.

#### Уку

Татар алфавитындагы хәрефләрне таный белү;

хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;

дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;

тексттагы тыныш билгеләренә карата тиешле пауза һәм интонацияләрне үтәү, өтерләр янындагы сүзләрне тиңдәшлек, эндәшү интонацияләре белән уку;

укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;

кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;

укыганда, сүзлекләр куллана белү.

### Язу

Татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;

дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;

бәйрәмнәр белән котлау, чакыру кәгазьләре язу;

конверт һәм дәфтәр тышына яза белү;

программада күрсәтелгән темалар буенча, терәк сүзләр кулланып, хикәя язу күнекмәләре формалаштыру.

## 5—9 нчы СЫЙНЫФЛАР

### Тыңлап аңлау

Төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү;

сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;

аутентик яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, информацион характердагы текстларны, газета-журналлардан мәкаләләрне тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралашуга чыга белү;

сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

### Диалогик сөйләм

Сорау, җавап, килеш(мә)ү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып әңгәмә кору, сөйләшә белү;

аралашуда катнаша, аны туктата һәм яңадан башлый белү;

парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү;

терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү;

татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән урынлы файдаланып әңгәмә кору, сөйләшә белү.

### Монологик сөйләм

Программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә текст төзи һәм аның эчтәлеген сөйли белү;

конкрет ситуациягә үз карашыңны, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү;

монологик сөйләмдә кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерә белү;

өйрәнгән текстны үз сүзләрең белән сөйләп бирә белү;

өйрәнгән шигырьләрне яттан сәнгатьле сөйли белү.

### Уку

Программада тәкъдим ителгән текстларны, татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;

текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү;

таныш булмаган текстны эчтән укып, аның төп фикерен таба белү;

таныш булмаган сүзләрнең, төзелмәләрнең тәрҗемәсен сүзлектән таба белү.

### Язу

Өйрәнелгән темалар буенча актив кулланууда булган сүзләрне дөрес яза белү;

конкрет бер тема буенча хикәя төзи белү;

прагматик текстлар (рецептлар, белдерүләр, афиша һ.б.), эпистоляр жанр текстлары (хатлар, котлаулар һ.б.) яза белү;

үзеңне борчыган проблемага карата фикерләреңне язмача җиткерә белү;

тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп, аны үзгәртеп яки дәвам итеп яза белү.

## 10—11 нче СЫЙНЫФЛАР

### Тыңлап аңлау

Әңгәмәдәшеңнең татарча сөйләмен тулысынча аңлау;

теле-, радиотапшыруларны тыңлап, өлешчә аңлау.

### Диалогик сөйләм

Аралашу процессында төрле репликаларны кулланып, үз фикереңне әңгәмәдәшеңә аңлата белү;

конкрет проблема буенча әңгәмәдәшең белән бәхәсләшә һәм үз фикереңне дәлилли белү;

программада тәкъдим ителгән проблема буенча әңгәмәдәшләрең белән аралашуга чыгу.

### Монологик сөйләм

Җанлы сөйләмнең төп фикерен атый, аңа үз карашыңны әйтә, яңа мәгълүматны чагыштыра һәм бәяли белү;

гади һәм программада күрсәтелгән кушма җөмләләрне кулланып, тормышта булган хәлләр, ишеткән яңа мәгълүматлар, үзеңне борчыган проблемалар турында хәбәр итә белү;

программада тәкъдим ителгән әхлакый проблемалар буенча үз фикереңне белдерә белү.

### Уку

Программада тәкъдим ителгән текстларны, татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;

укыган текстның эчтәлеген логик бөтеннәргә бүлә белү, план төзи белү.

### Язу

Укылган әсәр герое турында үз фикереңне язу;
күргән һәм ишеткән турында хикәяләп язу;
рәсми кәгазьләрне (гариза, автобиография, характеристика, резюме) яза белү;
әхлакый проблемага карата үз фикерләреңне язу, иҗади биремнәр эшләү.

## КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ НИГЕЗЕНДӘ ТӨЗЕЛГӘН ПРОГРАММАГА ЭЧТӘЛЕК САЙЛАУ ПРИНЦИПЛАРЫ

Коммуникатив технология нигезендә укыту процессын оештыру өчен, бу технология билгеләгән максатларга һәм принципларга туры килгән программа эчтәлеген сайлау таләп ителә. Димәк, коммуникатив технология нигезендә укыту принципларын ачыклау, программа эчтәлеген сайлау өчен, төп критерий, норматив база булып тора (Е. И. Пассов, В. Г. Костомаров, О. Д. Митрофанова, Э. П. Шубин, В. Ф. Габделхаков һ. б.).

Бу принципларның эчтәлеге нидән гыйбарәт соң?

### 1. Телне аралашу аша өйрәнү принцибы

Атаклы психологлар А. Н. Леонтьев, П. Я. Гальперин хезмәтләре күрсәтүенчә, белемнәрне үзләштерү аларны нинди дә булса эшчәнлектә куллану аша бара. Башта белемнәр суммасы булдырып, аннан соң аны практикада кулланырга мөмкин дип уйлау хәзерге дидактик таләпләргә җавап бирми. Сөйләмгә өйрәтү процессы башта аерым сүзләр, грамматик категорияләр өйрәнеп, аннан шулар нигезендә сөйләм оештыру аша барса, бу бик әйләнеч, нәтиҗәсез юл булыр иде. Коммуникатив технология нигезендә эчтәлек сайлау стратегиясе һәм тактикасы түбәндәгедән гыйбарәт: башта балаларның яшь үзенчәлегенә карап, аларның аралашү сфералары, аралашу ситуацияләре ачыклана, аннан соң шул сфераларда сөйләшүне оештыра алырлык лингвистик материал сайлана. Бу процесс түбәндәге схемада күрсәтелә.

Лингвистик материал сайлау схемасы

**Социаль контактлар, аралашу сфералары, ситуацияләрне ачыклау**

↓

**Сөйләшү, сөйләм предметын билгеләү**

↓

**Сөйләм бурычларын ачыклау**

↓

**Тиешле лингвистик материалны сайлау**

Әлбәттә, эчтәлек сайлаганда, сөйләм материалының күләмен билгеләү өчен, балаларның психофизиологик мөмкинлекләрен исәпкә алу зарур.

Югарыда әйтелгәннәрне искә алып сайланган материал мәктәптә телгә өйрәтү шартларын телне тормышта куллану шартларына якынлаштыру мөмкинлеген тудыра.

### 2. Уку процессын индивидуальләштерү принцибы

Россия Федерациясенең мәгарифне үстерү доктринасында күрсәтелгәнчә, хәзерге заман белем бирү системасы үсешенең төп юнәлеше — укыту процессын укучыларның шәхси ихтыяҗларын, теләкомтылышларын, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру.

Башлангыч сыйныф укучылары эмоциональ, хәрәкәтчән булалар, тиз арыйлар. Бала материалны үзе өчен кызык булса гына, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килсә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Күрсәтелгән психологик үзенчәлекләрнең, һичшиксез, эчтәлек сайлаганда исәпкә алынуы зарур.

Башлангыч сыйныфларда укыту процессында әкияти, фантастик сюжетлар, кызыклы геройлар белән очрашу, уен элементларын куллану тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә.

Урта һәм югары сыйныф укучылары өчен программада эчтәлек әхлакый проблемалар тирәсенә туплана. Әйтик, «Белем һәм тормыш» темасында «Яхшы уку өчен, нинди сыйфатлар кирәк?», «Яхшы уку җиңелме?» проблемалары буенча сөйләшүләр оештырыла, ә дәреслеккә бу проблемаларны чагылдырган әдәби әсәрләрдән өзекләр сайлана. Аңлашыла: бу әхлакый проблемалар, нигездә, балаларның тормыштагы төрле мөнәсәбәтләрен чагылдыра. Шунлыктан укучыларда бу мөнәсәбәтләргә карата үз фикерләрен әйтү, димәк, сөйләшергә теләү ихтыяҗы туа. Укучы укытучы кушканга түгел, ә үз теләге, үз ихтыяры белән сөйләм эшчәнлегенә тартыла.

### 3. Телне актив фикерләү нигезендә өйрәнү принцибы

Белем алу процессын укучыларның актив фикерләвенә нигезләп оештыру — психология һәм педагогика фәннәренең алдынгы вәкилләре куйган төп таләпләрнең берсе (С. Л. Рубинштейн, И. Я. Лернер, А. М. Матюшкин, М. И. Мәхмүтов, М. Н. Скаткин, И. А. Зимняя, И. Л. Бим, Е. И. Пассов, Л. З. Шакирова, В. Ф. Габделхаков, Ф. Ф. Харисов, Р. З. Хәйдәрова).

Психологлар, методистлар фикеренчә, материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе,— тел өйрәнү өчен, күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Димәк, эчтәлектә аралашу ситуацияләре һәм ситуатив күнегүләр системасы булу мәҗбүри. Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, укучылар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шундук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа, һәм тел өйрәнү процессының мо-

тивлашкан булуы тәэмин ителә. Шуңа күрә программада, һәр сыйныфта аралашу өчен, коммуникатив максатлар, өлкән сыйныфларда аралашу проблемалары күрсәтелеп барды. Лингвистик материал һәм сөйләм үрнәкләре программада нәкъ менә коммуникатив максаттан, аралашу проблемаларыннан чыгып билгеләнде.

### 4. Телне функциональ төстә өйрәнү принцибы

Коммуникатив методикага нигез салучыларның берсе Э.П. Шубин мәктәптә чит телне өйрәтү процессында грамматик материалны академик грамматика эзлеклелегендә һәм тирәнлегендә өйрәнүне мәҗбүр итеп куймый. Функциональ принцип нигезендә программага грамматик материал түбәндәге таләпләр буенча сайлана:

— грамматик материал коммуникатив максаттан, аралашу ихтыяҗыннан һәм кулланыш ешлыгыннан чыгып билгеләнә;

— грамматик материалның күләме, теоретик катлаулылыгы укучыларның үзләштерү мөмкинлекләрен исәпкә ала;

— грамматика тел берәмлеге буларак түгел, ә сөйләм берәмлеге буларак өйрәнелә; иң беренче чиратта грамматик категориянең формасына түгел, ә аның функциясенә игътибар ителә: хәбәр итү, аңлату, сорау, тәкъдим итү, киңәш бирү, ышандыру һ.б.

Башлангыч этап өчен грамматик материал күрсәтелгән критерийларга таянып сайланды. Грамматик материалның бер өлеше теоретик формада бирелмичә, ә лексик-грамматик төзелмәләр формасында тәкъдим ителде. Аларны үзләштерү сөйләм ситуацияләре нигезендә оештырыла. Ә җиңелрәк дип саналган грамматик материал филологик формада, кагыйдәләр нигезендә өйрәнелә бара. Ләкин кагыйдәләрне ятлау мәҗбүри түгел, аларны аралашуда куллануны имитацияләүгә игътибар ителә.

Урта һәм югары звенода грамматик материал, нигездә, филологик формада, грамматик кагыйдәләр нигезендә тәкъдим ителде.

### 5. Ана телен исәпкә алу принцибы

Башка телне өйрәнү вакытында, бала ихтыярсыз рәвештә лингвистик материалны ана теле күренешләре белән чагыштыра. Бу телне үзләштерү процессын җиңеләйтә. Димәк, һәр сыйныфка программа материалын сайлаганда, балаларның ана теле буенча белемнәр системасын исәпкә алу зарур. Яңа грамматик кагыйдәләр бары тик ана телендә өйрәнелгәннән соң гына кертелә бара, ә дәреслекләрдә грамматик кагыйдәләрнең рус һәм татар телендә бирелүе укучыларның белем сыйфатын күтәрүгә зур этәргеч булып тора.

# ПРОГРАММАНЫҢ ТЕМАТИК ЭЧТӘЛЕГЕ

## 1 нче СЫЙНЫФ (168 сәгать)

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Әйдәгез, танышабыз!** (20 сәгать) | | |
| Әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра белү. Сорау куя, әңгәмәдәшеңнең хәлен сорый, кире кага, раслый белү. Әңгәмәдәшеңнең яшәү урынын сорый һәм үзеңнең кайда яшәвең турында хәбәр итә белү. | Исәнме(сез)! Син кем? Мин — Оля. Мин — малай (кыз). Синең исемең ничек? Мин — Оля. Бу кем? Бу — Оля. Хәлләр ничек? Рәхмәт, яхшы. Бу Азатмы? Син Азатмы? Әйе, мин — Азат. Юк, ул Азат түгел. Сау бул(ыгыз). Син кайда яшисең? Мин Казанда яшим. | исәнме(сез), хәерле көн, мин, син, ул, бу, кыз, малай, укучы, укытучы, хәлләр, ничек? кем? нәрсә? исем, сау бул, яхшы, әйе, юк, түгел, ул, кайда? шәһәр исемнәре, яши, авыл, шәһәр, ничә? яшь, Татарстан, Россия, ә, уйныйбыз, әйдә, ярый, Шүрәле, бала, күбәләк, эт, песи, Акбай, урман |
| Бер-береңнең яшен сорый һәм җавап бирә белү. Уенга чакыра, риза була белү. | Сиңа ничә яшь? Миңа 7 яшь. Алсуга 7 яшь. Сиңа 7 яшьме? Әйдә, бергә уйныйбыз. Ярый. | 1—10 га кадәр саннар, ничәнче |
| **Йорт хайваннары һәм кошлары, кыргый хайваннар** (34 сәгать) | | |
| Йорт хайваннары һәм кошлары, кыргый хайваннарның, кошларның исемнәрен атый, саный, яшәү урыннарын әйтә, аларны характерлый белү. | Бу нәрсә? Бу — аю. Ул урманда яши (яшәми). Аю зур, усал. Ничә аю бар? 3 аю бар. Бу — зур аю түгел, кечкенә аю. Аю Татарстанда яшиме? Балык йөзә, куян йөгерә, кош оча. Куян дус, кил монда. Булат Акбай белән уйный. Ул беренче килә. Оля ничек йөгерә? | сарык, сыер, ат, кәҗә, дуңгыз, кош, этәч, тавык, чеби, каз, үрдәк, куян, аю, бүре, төлке, тиен, керпе, кояш, оча, фил, жираф, арыслан, Шүрәле, агач, алмагач, сандугач, укый, утыра, монда, җир, су, зур, кечкенә, усал, хәйләкәр, куркак, йөзә, сикерә, оча, йөгерә, бара, кайта, нишли? нишлиләр? кил, дус, әле |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Мәктәптә** (10 сәгать) | | |
| Уку-язу әсбапларының исемнәрен әйтә, иптәшеңә тәкъдим итә, санын әйтә, сорап ала белү.<br><br>Предметларның урынын әйтә белү.<br><br>Уку хезмәтен атый, үзеңнең, иптәшеңнең ничек укуын әйтә белү. | Бу нәрсә? Бу — китап. Ничә китап бар? 2 китап бар. Миңа дәфтәр кирәк. Сиңа китап кирәкме? Миңа дәфтәр бир әле. Мә дәфтәр. Рәхмәт. Бу китапмы? Юк, бу китап түгел.<br>Китап кайда? Китап сумкада. Сумкада каләм бармы?<br>Укучы нишли? Укучы укый, яза, саный, җырлый, рәсем ясый. Ничек яза? Чиста яза, яхшы укый, каләм белән яза. | дәфтәр, китап, бетергеч, каләм, акбур, дәрес, рәсем, карандаш, такта, татар теле, нишли? укый, яза, рәсем ясый, җырлый, мәктәп, бүген, бар, кирәкме? дөрес, такта, нинди? ничек? пычрак, чиста, яхшы, матур, кирәк(ми), рәхмәт, кайда? өстәлдә, укучы, укытучы, начар, бас, утыр, татар теле, җыр |
| **Бакчада, базарда** (12 сәгать) | | |
| Яшелчә исемнәрен, санын, аларның төсен, тәмен әйтә, аларны сорап ала белү.<br>Нинди яшелчә яратканыңны әйтә белү. Базарда яшелчә, җиләк-җимеш сатып ала белү. | Син кая барасың? Мин базарга барам. Нәрсә аласың? Бу — кыяр. Кыяр яшел. Миңа кыяр бир (егез) әле. Бакчада нәрсә үсә? Шалкан, кишер, ... .<br>Син нәрсә яратасың? Мин кыяр яратам. Тәмлеме?<br>Алма бармы? Алма ничә сум? Миңа алма бирегез әле. Мин кызыл чәчәк яратам. Оля, мә кызыл чәчәк. | кишер, яшелчә, помидор, шалкан, алма, кыяр, бәрәңге, суган, кәбестә, җиләк, кызыл, зәңгәр, яшел, ак, кара, сары, тәмле, тәмле түгел, яратам, бир әле, мә, ал, ничә сум, бирегез әле, чия, карлыган, әфлисун, җыя, чәчәк |
| **Кыш** (16 сәгать) | | |
| Кыш билгеләрен әйтә белү.<br>Кышкы уен төрләрен әйтә белү, уенга чакыра белү.<br><br>Яңа ел, чыршы, Кыш бабай һәм Кар кызы исемнәрен атый белү. | Көн салкын. <...><br>Мин чаңгы шуам. Әйдә, чана шуабыз. Син ничек шуасың? Мин яхшы шуам. Әйдә, шугалакка барабыз.<br>Яңа ел бәйрәменә кемнәр килә? Кыш бабай, Кар кызы килә. Кыш бабай бүләк алып килә. Мин бәйрәмгә барам. | кыш, салкын, кар ява, җил, исә, буран, чаңгы, чана, әкрен, ярый, шуа, тау, Яңа ел, Кыш бабай, Кар кызы, чыршы, яшел, җитә, уенчык, шар, килә, бәйрәм, котлый |
| **Гаилә, өйдә булышу** (10 сәгать) | | |
| Гаилә әгъзаларының исемнәрен атый, гаиләдә | Бу — безнең гаилә. Безнең гаилә зур түгел. | әни, әти, апа, абый, сеңел, эне, әби, бабай, бә- |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| кемнәр, ничә кеше барлыгын әйтә белү.<br><br>Татар халык ашлары исемнәрен атый, нинди ашлар пешергәнне әйтә белү. | Бу — минем әтием. Аның исеме — Александр Львович.<br>Әни бәлеш пешерә. Гөбәдия бик тәмле. Мин гөбәдия ашыйм, чәй эчәм. | леш, гөбәдия, чәкчәк, өчпочмак, ипи, эшли, пешерә, ит, савыт-саба, тәлинкә, чынаяк, чәнечке, кашык, пычак, эчә, ашый, өй, тату, кунак, булыша, ю, юа, тәмле, идән |
| | **Кунакта** (10 сәгать) | |
| Ашарга, чәй эчәргә чакыра белү.<br>Нәрсә яратуыңны әйтә белү.<br>Керергә рөхсәт сорый белү.<br>Туган көн турында сөйли белү.<br><br>Туган көн вакытын әйтә белү. | Оля, чәй эч, аш аша.<br>Син нәрсә яратасың? Мин варенье яратам. Мин варенье белән чәй эчәм.<br>Керергә ярыймы? Әйдә, уз.<br>Бүген туган көнем. Без җырлыйбыз, уйныйбыз.<br>Синең туган көнең кайчан?<br>5 нче августта. | кунак, ярый, ярамый, уз, туган көн, кайчан? |
| | **Кибеттә** (10 сәгать) | |
| Ашамлык исемнәрен әйтә, кибеттән сатып ала белү.<br>Савыт-саба исемнәрен әйтә, аларны кибеттән сатып ала белү. | Сөт бармы? Сөт ничә сум тора? Миңа сөт бирегез әле.<br>Бу — кашык. Кашык бармы? Кашык ничә сум тора? Синең кашыгың бармы? | сөт, май, чәй, ипи, сыр, шикәр, конфет, кефир, сок, чынаяк, чәйнек, тәлинкә, чәнечке, кашык, пычак |
| | **Яз** (9 сәгать) | |
| Яз билгеләрен әйтә белү.<br>Ел фасылының ни өчен ошаганын әйтә белү.<br>8 нче Март бәйрәме белән котлый белү.<br><br>Нинди бүләк бирүеңне әйтә белү. | Яз җитә. Тамчы тама, көн җылы, кар эри, кошлар килә.<br>Әнием, сине 8 нче Март белән котлыйм. Сиңа бәхет телим.<br>Мин әнигә чәчәк бирәм. | яз, тамчы тама, эри, рәхәт, ошый, кошлар килә, көн җылы, яз җитә, ни өчен? котлыйм, бәхет телим, бүләк, 8 нче Март |
| | **Без шәһәрдә яшибез** (10 сәгать) | |
| Үзең яшәгән шәһәр (авыл) турында сөйли белү.<br><br>Нинди республикада яшәгәнеңне әйтә белү. | Мин шәһәрдә яшим. Безнең шәһәр бик матур. Шәһәрдә автобуслар йөри.<br>Мин Татарстанда яшим. | безнең, бик, матур, зур, киң, урам, йөри, Татарстан шәһәрләре исемнәре |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| Нинди транспортта барганыңны әйтә белү. | Мин мәктәпкә автобуста барам. | |
| **Сәламәт бул!** (10 сәгать) | | |
| Тән әгъзаларының, шәхси гигиена предметларының исемнәрен атый, ул предметларны сорап ала белү.<br><br>Кайсы жирең авыртуы турында әйтә белү.<br>Авыру кешенең хәлен сорау, аңа дару, чәй тәкъдим итә белү. | Бу — баш, күз, ... <...> Миңа сабын бир әле. Синең сөлгең нинди? Мин бит юам, теш чистартам. Кулың чистамы? Башым авырта. Синең башың авыртамы? Әйе, авырта. Юк, авыртмый. Әби, хәлең ничек? Температураң бармы? Мә, дару (чәй) эч. | баш, бит, чәч, борын, колак, авыз, кул, күз, аяк, бармак, авырта, сабын, тарак, сөлге, теш щёткасы, чистарта, сикерә, сөртә, тарый |
| **Киемнәр кибетендә** (9 сәгать) | | |
| Кием исемнәрен әйтә белү, аларның төсен әйтү, нинди кием яратканыңны әйтә белү. | Күлмәк матур, зәңгәр. Мин зәңгәр күлмәк яратам. Синең кызыл күлмәгең бармы? | чалбар, итек, яулык, итәк, бүрек, бияләй, башлык, күлмәк, сум |
| **Җәй** (8 сәгать) | | |
| Җәйге табигать, җәйге ял турында сөйли белү. | Җәй житә. Көн җылы. Җиләкләр, чәчәкләр үсә. Мин урманда җиләк җыям. Мин авылга (бакчага) барам. Җәй көне Сабантуй була. | җәй, көн, елга, күл, җиләк, гөмбә, Сабантуй |

## Грамматик минимум

1. Исемнәрнең берлек һәм күплек саннары.
2. Исемнәргә *кем? нәрсә?* сорауларын куя белү.
3. Исемнәрнең I, II, III затта берлек санда тартым белән төрләнеше белән таныштыру.
4. Исемнәрнең урын-вакыт, юнәлеш, чыгыш килешләрендә төрләнеше белән танышу.
5. Зат алмашлыкларын берлек санда сөйләмдә куллану.
6. *-мы/-ме, түгел* кисәкчәләрен, хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасын (*-мый/-ми*) сөйләмдә куллану.
7. *Кайда? Кая? Кайдан?* сорауларын кулланып төзелгән сорау җөмләләр белән таныштыру.
8. Микъдар һәм тәртип саннары белән таныштыру (1—20 саннары).
9. *Ничә? Ничек? Нинди? Нишли? Кайчан?* сорауларына җавап бирә белү.
10. *Белән* бәйлеген сөйләмдә исем белән куллану.

11. Хәзерге заман хикәя фигыленең I, II, III зат берлек сан формаларын сөйләмдә куллану.

12. Боерык фигыльнең II зат берлек һәм күплек сан формалары белән таныштыру.

13. *Бу* күрсәтү алмашлыгын сөйләмдә куллану.

14. *Сыйфат+исем* төзелмәсен сөйләмдә куллану.

15. *Һәм* теркәгечен сөйләмдә куллану.

16. *Сан+исем* төзелмәсен сөйләмдә куллану.

17. *Без* зат алмашлыгының сөйләмдә кулланышы белән танышу.

## Орфографик һәм орфоэпик минимум

1. Сузык һәм тартык авазлар, аларның аермасы. Калын һәм нечкә сузыклар. Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аерырга өйрәнү.

2. Татар һәм рус телләрендәге сузык һәм тартык авазларны чагыштырып, дөрес әйтә белү, транскрипция билгеләре белән таныштыру.

3. Озын һәм кыска сузыкларны сүзләрдә дөрес итеп әйтә белү.

4. Татар хәрефләренең кабул ителгән формаларын дөрес язу.

5. Сүз басымы. Сүзләрдә басымны дөрес кую.

6. Хикәя һәм сорау җөмләләрне интонацион яктан дөрес әйтергә гадәтләндерү. Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен дөрес куеп язарга күнектерү.

7. Ялгызлык исемнәрен баш хәрефтән башлап язарга өйрәтү.

8. Матур һәм дөрес язу күнекмәләре булдыру.

9. Боеру максаты белән әйтелгән җөмләләрне аңларга өйрәтү.

## 2 нче СЫЙНЫФ (168 сәгать)

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Без мәктәпкә барабыз** (20 сәгать) | | |
| Беренче сентябрь турында сөйли белү.<br><br>Уку-язу әсбапларының барлыгын, юклыгын, кирәклеген хәбәр итә һәм сорап ала белү.<br>Уку хезмәте турында сорый, сөйли белү.<br>Укучының уку хезмәтенә бәя бирү.<br><br>Бер-береңнең ничәнче сыйныфта укуын сорый һәм җавап бирә белү. | Бүген беренче сентябрь. Көн матур, җылы, кояшлы. Мәктәптә музыка уйный.<br>Синең дәфтәрең бармы? Сиңа дәфтәр кирәкме? Миңа дәфтәр бир әле.<br><br>Айрат күнегү эшли (эшләми). Айрат укыймы? Айрат яхшы укый. Айрат нинди билге ала? Айрат «4»ле ала.<br>Син ничәнче сыйныфта укыйсың? Мин икенче сыйныфта укыйм. | кояшлы, уку елы, башлана, сорау бир, җавап бир, сөйли, тыңлый, дәреслек, көндәлек, ел, куя, өй эше, җөмлә, нокта, кичә, кабатлый, билге, «дүрт»ле («биш»ле), күңелле, шигырь, дөрес, хәреф, аваз, иҗек, мисал, мәсьәлә, тырыш, яхшы |
| **Көз җитә** (15 сәгать) | | |
| Көз билгеләрен әйтә белү. | Көз җитә. Урамда салкын. Көннәр кыска, төн озын. Кошлар җылы якка китәләр. | көз, көз көне, көн, төн, җил, яфрак коела, исә, яңгыр, алтын, ай, җылы як, елга, китә |
| **Базарда** (15 сәгать) | | |
| Җиләк-җимеш исемнәрен, төсен, тәмен, нәрсә яратуыңны әйтә белү.<br>Базарга барырга чакыра, кем белән барганыңны әйтә белү.<br>Базарда җиләк-җимеш сорап ала белү. | Груша сары, баллы. Син нәрсә яратасың? Мин карбыз яратам.<br>Әнием, әйдә, базарга барабыз. Мин базарга әнием белән барам.<br>Әйтегез әле, карбыз ничә сум тора? | 11—20 гә кадәр саннар, ачы, түгәрәк, баллы, чия, карлыган, алма, лимон, груша, слива, миләш, кура җиләге, карбыз |
| **Мин чисталык яратам** (15 сәгать) | | |
| Шәхси гигиена предметларының нинди икәнен, аларны кулланып, нәрсә | Сөлге нинди? Ул чиста, йомшак, матур ... . Мин сөлге белән бит сөртәм. | тамак, муен, үлчи, авырый, чәч тарый, теш чистарта, әйбәт, пөхтә, белән, |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| эшләгәнеңне әйтә, сорый белү.<br>Бер-береңә комплимент әйтә белү.<br>Табибка кайсы җиреңавыртуны әйтә белү.<br>Авыру кешегә киңәш бирә белү. | Тарак белән чәч тарыйм.<br>Синең бантигың матур.<br>Кайсы җирең авырта? Минем башым авырта. Температураң бармы?<br>Дару эч, бал белән чәй эч. | сөлге, авырый, авырта |
| **Гаилә. Өйдә булышу** (20 сәгать) | | |
| Гаилә турында сөйли белү. Гаиләдә кемне яратканыңны әйтә белү.<br>Өй эшләрендә булышу турында сөйли белү.<br>Бер-береңне табынга чакыру, кыстау, ашаганнан соң рәхмәт әйтү, бер-береңнең нәрсә яратканын сорый һәм җавап бирә белү. | Безнең гаиләдә биш кеше: әни, ... . Мин әнине яратам.<br>Син өйдә нишлисең? Мин әнигә булышам. Мин савыт-саба юам, гөлгә су сибәм.<br>Айдар, утыр! Өчпочмак аша. Нинди матур табын! Рәхмәт, өчпочмак бик тәмле. Син чәкчәк яратасыңмы? | дәү әни (әти), бергә, ял итә, иртәнге аш, көндезге аш, кичке аш, әзерли, өстәл, кыстыбый, әйбәт, йомырка, ботка, уң як, сул як, сала, сөртә, кисә, ял көне, өстәл җыештыра, гөл, су сибә |
| **Кыш** (23 сәгать) | | |
| Кышкы табигатьне сурәтли белү.<br>Һава торышын сорый белү.<br>Кыш көне кошларга булышу турында әйтә белү.<br>Яңа ел бәйрәме турында сөйләшә белү.<br>Кышкы уен төрләрен әйтә, уенга чакыра, уенга чыгарга ризалашу, ризалашмауның сәбәбен әйтә белү.<br>Яңа ел бәйрәме белән котлый белү.<br>Образларны характерлый белү. | Кыш җитте. Салкын җил исә, кар ява.<br>Урамда салкынмы? Әйе, салкын.<br>Без кошларга җимлек ясыйбыз, җим бирәбез. Син җимлек ясадыңмы?<br>Мәктәптә чыршы бәйрәме була. Син бәйрәмдә нишлисең? Мин бәйрәмдә җырлыйм.<br>Әйдә, тауга барабыз, чаңгы шуабыз. Мин шумыйм, чанам юк.<br>Оля, сине Яңа ел бәйрәме белән котлыйм.<br>Нәсим саран, ул чана бирмәде. | тукран, песнәк, ала карга, бөтен, көлә, һәм, шатлана, биек, янында, тимераяк, каплый, кыш айлары, җимлек, көтә, кар бабай, Кар кызы, бии, күгәрчен, чыпчык, җим, риза, риза түгел, саран, юмарт, тәрбияле |
| **Туган җирем** (25 сәгать) | | |
| Бер-береңнең яшәү урын сорый һәм кайда яшәгәнеңне әйтә белү. | Син кайда яшисең? Мин Татарстанда яшим. Син нинди районда, шәһәрдә (авылда) яшисең? | туган як, озын, киң, аз, Идел, Нократ, Ык, Агыйдел, Кама, ут яна, туктый, аша, чыга, бара, йорт, |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| Татарстан шәһәрләренең, елгаларының исемнәрен әйтә белү.<br>Татарстанда яшәгән хайваннарны әйтә, аларны сурәтли белү.<br>Нинди транспортта барганыңны әйтә белү. Юл йөрү кагыйдәләрен әйтә белү.<br>Авыл турында сөйли белү. | Татарстанда Идел, ... елгалары бар.<br>Татарстанда аю, бүре, ... яши. Миңа куян ошый. Ул тиз йөгерә, матур.<br>Нинди транспортта барасың? Автобуста барам. Светофорда яшел ут яна — мин юл аша чыгам. Светофорда кызыл ут яна — мин туктыйм.<br>Авыл янында урман бар. Без урманга барабыз. Авылда күңелле, рәхәт. | буенда, поши, күңелле |
| **Кибеттә** (15 сәгать) | | |
| Киемнәрнең исемнәрен, аларны сатып ала, бәяләрен сорый белү.<br>Бер-береңнең киеменә комплимент әйтә белү.<br>Ашамлыклар сатып ала белү. | Бу нинди кибет? Кибеттә нәрсәләр бар? Сания күлмәк кия. Күлмәк ничә сум тора?<br>Гөлшат, син бүген бик матур.<br>Миңа 2 кг алма бирегез әле. Ипи , шикәр бармы? | калфак, түбәтәй, сарафан, тун, кия, ошый, сата, сатып ала, ерак, якын, тоз, үлчи, он, акча |
| **Җәй** (20 сәгать) | | |
| Җәй турында сөйли белү.<br>Каникулны ничек үткәрү турында сөйләшү.<br>Сабантуйда катнашу турында сөйләшү. | Менә ямьле җәй житте. Җәй көне җылы, рәхәт. Көн кояшлы.<br>Син җәй көне кая барасың? Мин авылга кайтам.<br>Оля, син Сабантуйга барасыңмы? Сабантуйда нинди уеннар була? Чүлмәк ваталар, көрәшәләр. | ямьле, кыздыра, күбәләк, эссе, җәйге, түгәрәк, ерак, болын, ошый, балан, күбәләк, су керә, кызына, баганага менә, уен, чүлмәк, көрәшә |

## Грамматик минимум

1. *Без, сез, алар* алмашлыкларын сөйләмдә куллану.

2. Исемнең төшем килешендә төрләнеше белән таныштыру.

3. *Кем? Нәрсә? Кайда? Кая? Кайдан? Нинди? Ничек? Ничә? Ничәнче?* сорауларына җавап бирә, аларны кулланып, сораулар бирә белү.

4. Исемнәрнең берлек санда тартым белән төрләнешен гамәли үзләштерү.

5. *Әле, бик* кисәкчәләрен сөйләмдә куллану.

6. Боерык фигыльнең барлык һәм юклык формалары белән таныштыру.

7. Хәзерге заман хикәя фигыльнең I, III зат юклык формасын сөйләмдә куллану.

8. *Астында, өстендә* бәйлек сүзләрен сөйләмдә куллану белән таныштыру.

9. Хәзерге заман хикәя фигыльнең I, II, III зат күплек формасын сөйләмдә куллану.

10. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта берлек сан III зат формасы белән таныштыру.

11. *Мин, син* зат алмашлыкларын юнәлеш килешендә сөйләмдә куллану.

12. 11 дән 100 гә кадәр саннарны сөйләмдә куллану.

13. *Сабын белән юына* төзелмәсен сөйләмдә куллану.

14. *Ә* теркәгечен сөйләмдә куллану.

15. Сыйфатның гади дәрәҗәсен сөйләмдә куллану.

16. *Кирәк, кирәк түгел, ярый, ярамый* сүзләрен сөйләмдә куллану.

## Орфографик һәм орфоэпик минимум

1. Сузык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны дөрес әйтү һәм дөрес язу күнекмәләрен камилләштерү. Сингармонизм законы. Татар теленең үзенчәлекле сузыклары һәм аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Сүзләрне транскрипция билгеләре белән яза белү.

2. Тартык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау авазлар. Аларны дөрес әйтә һәм дөрес язу күнекмәләрен камилләштерү.

3. Татар алфавитын яттан өйрәнү.

4. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Укылган иҗекләр санын билгели белү.

5. Аралашу өчен бирелгән темаларга караган сүзләрнең дөрес әйтелешенә ирешү.

6. Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен интонациягә бәйле рәвештә кую.

# 3 нче СЫЙНЫФ (168 сәгать)

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Яңа уку елы котлы булсын!** (20 сәгать) | | |
| Яңа уку елы белән котлый белү.<br><br>Яңа уку елына әзерлек, нинди уку-язу әсбаплары кирәклеге турында сөйләшү.<br>Өй эшләрен эшләү турында фикер алышу.<br>Үзең укыган сыйныф турында мәгълүмат бирә белү.<br>Мәктәптә дежурлык хезмәте турында сөйли белү.<br>Китапханәгә барырга чакыру, нинди китаплар уку турында сөйләшү. | Яңа уку елы белән котлыйм. Син бүген бик матур.<br>Син нинди дәфтәрләр алдың? Минем сумкам яңа.<br>Синең өй эшең бармы? Мисал эшлим, мәсьәлә чишәм.<br>Безнең сыйныфта 25 укучы: 10 малай, 15 кыз. <...><br>Дежур укучы нишләде? Ул тәрәзә ачты, тактаны сөртте, ... .<br>Син китапханәгә барасыңмы? Әйдә, китапханәгә барабыз. Син нинди китап укыдың? | башлана, уңыш, тели, килешә, тарата, ятлый, чишә, такта сөртә, тәрәзә ача, хезмәт, хата, хаталы(сыз), яза, күчерә, аңлата, китапханә, китапханәче, кызыклы, әкиятләр, хикәя, ярдәм, турында, дистә саннары: ун, егерме, утыз, кырык |
| **Ашханәдә** (20 сәгать) | | |
| Мәктәп ашханәсе, пешерелгән ашлар турында сөйли белү.<br>Үзеңә кирәк ризыкны сорап ала белү.<br>Табын әзерләү турында сөйләшү.<br>Табын янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен сөйли белү. | Безнең мәктәптә ашханә бар. Без ашханәдә ашыйбыз. <...><br>Миңа өчпочмак кирәк.<br><br>Мин өстәлгә тәлинкә куям. Тәлинкә янына ... .<br>Әдәпле кеше кулын юа, чиста ашый. Табын янында сөйләшми. | ашханә, токмачлы аш, кәбестә ашы, дөге боткасы, каймак, кесәл, төрле, кайнар, пилмән, кош теле, идән, төште, тәлинкә янына, тук, ач, ватыла, вата, аш вакыты, ялган, ялганлый, әдәпле |
| **Көндәлек режим** (14 сәгать) | | |
| Сәгать ничә икәнен, эшнең сәгать ничәдә башкарылганын әйтә белү.<br><br>Көндәлек режим турында сөйли белү. | Сәгать ничә? Сәгать унике. Сәгать ничәдә киләсең? Мәктәптән сәгать ничәдә кайтасың?<br>Мин сәгать 7дә торам. Ашыйм, мәктәпкә китәм. | сәгать, йокы, тора, зарядка ясый, файдалы, шатлана, мактый, көндез, кичә, иртә, 11—100 гә кадәрге саннар |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Без әти-әниләргә булышабыз** (20 сәгать) | | |
| Г. Тукай турында сөйли белү.<br>Гаилә әгъзаларының кайда, кем булып эшләгәнен әйтә белү.<br>Өй эшләрендә катнашу турында әйтә, сорый белү.<br>Укылган әсәрләрдәге образларга бәя бирә белү. | Г. Тукай — бөек шагыйрь. <...><br>Минем әни — сатучы. Ул базарда эшли.<br>Мин әтигә булышам. Без әти белән кибеткә барабыз, ашамлыклар алабыз. Мин идән юам, ә син нишлисең?<br>Айдар — эшчән малай, чөнки ул әнисенә булыша. <...> | шагыйрь, шигырь, әсәр, өлкәннәр, кечкенәләр, булыша, су сибә, җир казый, тәрбияле, минемчә, синеңчә, сатучы, тегүче, эшче, үзем, тапты, алдында, артында, тиз, озак, эзләде, югалтты, җитез, әкрен, ялкау, тәртипле, тәртипсез, саф һава, эшчән, ялкау, үзе, белә, каршында, өстендә, астында, тәрәзә, эри |
| **Туган якка кыш килде** (20 сәгать) | | |
| Һава торышы турында сөйләшә белү.<br>Яңа ел бәйрәме турында сөйләшү.<br>Кышкы каникулны ничек үткәрү турында сөйләшү. | Көн нинди? Көн аяз, салкын, җил исә, буран. <...><br>Бәйрәмгә кайчан барасың? Кем белән барасың? Бәйрәм кайда була? Бәйрәмдә нишлисең?<br>Син кышкы каникулда нишләдең? Мин чаңгы шудым, компьютерда уйнадым. <...> | һава торышы, кар бөртеге, аяз, биек, шатланды, чаңгы ярышы, кинәт, егылды, сынды, ерак, ярдәм итә |
| **Без шәһәрдә (авылда) яшибез** (18 сәгать) | | |
| Үзең яшәгән шәһәр (авыл) турында мәгълүмат бирә белү.<br>Үз фатирың турында сөйли белү. | Безнең шәһәр матур, зур. Анда музейлар, театрлар бар, кибетләр күп. <...><br>Безнең авыл елга янында урнашкан. Йорт янында бакча бар. <...><br>Мин икенче катта, 57 нче фатирда яшим. Безнең фатирда өч бүлмә бар: йокы бүлмәсе, кунак бүлмәсе, аш бүлмәсе. | бүлмә, буенда, катлы, театр, музей, янында, йорт, фатир, кат, аш бүлмәсе, якты, йокы бүлмәсе, кунак бүлмәсе, юыну бүлмәсе, бакча, чишмә, агач |
| **Әдәпле булыйк!** (18 сәгать) | | |
| Табынга чакыра белү. Рәхмәт әйтә белү.<br>Туган көнгә чакыру әдәбе. | Табынга рәхим итегез! Олег, утыр, чәй эч, шикәр ал. Ашларыгыз тәмле булсын! Рәхмәт. Сезгә бик зур рәхмәт.<br>Саша, сине туган көнгә чакырам. Туган көн сәгать 2 дә башлана. | рәхим итегез, чакыра, тәмле булсын, ярты, барлык, буш, урын, егыла, әдәпле, тәртипле, акыллы, игътибарлы, шалтырый, чакырыгыз, борчый, шатлык, бәхет, сәламәтлек |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| Транспортта зурларга урын тәкъдим итә белү.<br><br>Телефоннан әдәпле сөйләшә белү.<br>Укылган хикәяләрнең эчтәлеге аша геройларның әдәпле булуына бәя бирә белү.<br>Өлкәннәрне, дусларыңны бәйрәмнәр белән котлый белү. | Илдар — әдәпле малай, чөнки ул әбигә урын бирә. Әби, монда буш урын бар, утырыгыз.<br>Исәнмесез, мин — Оля, миңа Алсу кирәк иде.<br>Айдар — тәртипле малай, әбигә булышты.<br><br>Сезне бәйрәм белән котлыйм. Сезгә сәламәтлек, шатлык, бәхет телим. | |
| **Кечкенә дусларыбыз (20 сәгать)** | | |
| Кышлаучы кошлар, аларга җимлекләр ясау турында сөйләшү.<br><br>Үзеңнең кечкенә дусларың (эт, мәче), аларның гадәтләре, тышкы кыяфәтләре, аларны карау турында сөйләшү. | Нинди кошлар бездә кышлый? Син кошларга җимлек ясадыңмы? Кая куйдың?<br>Минем этем бар. Ул бик матур, акыллы, хәйләкәр. Ул ак (кара) төстә. Акмуенның койрыгы йомшак, күзләре кечкенә.<...> | хәйләкәр, өрә, саклый, хуҗа, тәпи, терелә, тәрәзә, чукый, канат, куна, койрык, озын, кара карга, гадәт, тычкан, тышкы кыяфәт, маэмай, тыңлый, Акмуен, Акбай, Актырнак |
| **Күңелле җәй, ямьле җәй (18 сәгать)** | | |
| Җәй көне урманга бару, җиләк-җимеш җыю, бакчада булышу турында сөйләшү.<br>Балаларның яраткан җәйге уеннары турында сөйләшү.<br><br><br>Җәйге Сабантуй турында сөйләшү. | Мин урманга барам, урманда җиләк, гөмбә җыябыз.<br><br>Җәй көне су коенам, чумам, кызынам, балык тотам. <...><br>Мин футбол уйныйм.<br>Ә мин велосипедта йөрим.<br>Сабантуй — зур бәйрәм. <...> | җиләк, кып-кызыл, җыям, эре, күп, агулы, яңгыр, кызына, су коена, чума, балык тота, чүп утый, качышлы, әбәкле, туп, атта чаба, чүлмәк вата, баганага менә |

## Грамматик минимум

1. Исемнең иялек килешендә төрләнеше белән таныштыру.
2. Зат алмашлыкларын күплек санда юнәлеш килешендә сөйләмдә куллану.
3. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнеше.
4. Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең барлык һәм юклык формасы белән текст аша танышу.
5. *Уйнарга яратам* конструкциясе белән таныштыру.
6. Синоним һәм антоним сыйфатларны сөйләмдә куллану.

7. *Янында, алдында, астында, артында, өстендә* бәйлек сүзләрен һәм *турында* бәйлеген сөйләмдә куллану.

8. *Ләкин, чөнки, шуңа күрә* теркәгечле кушма җөмләләрнең эчтәлеген аңлап, аларны сөйләмдә куллану.

9. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатлар белән танышу.

10. Сүзнең тамырын, кушымчасын аера белү.

11. *-чы/-че* исем ясагыч кушымчалар белән таныштыру.

12. *Кебек* бәйлеген сөйләмдә куллану.

13. *Казан шәһәре, киемнәр кибете* төзелмәләре белән таныштыру.

14. *Аннан соң* рәвеше һәм *һәр, һәркем, барлык, барысы* алмашлыклары белән таныштыру.

### Орфографик һәм орфоэпик минимум

1. Өйрәнелгән лексик берәмлекләрне орфоэпия нормаларына туры китереп әйтүне ныгыту.

2. Алынма сүзләрне, дөрес әйтелешен саклап, сөйләмдә кулланырга күнектерү.

3. Укучыларның язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерү эшен дәвам итү.

4. Ике бертөрле тартык янәшә килгән сүзләрне дөрес әйтү һәм язу күнекмәләрен булдыру (китте, кайтты).

5. Янәшә килгән ике бертөрле тартык булган сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү.

6. *Я, ю, е* хәрефләре кергән сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын истә калдыру.

7. *О, ө* хәрефләренең беренче иҗектә генә язылуы.

# 4 нче СЫЙНЫФ (170 сәгать)

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Яңа уку елы котлы булсын!** (20 сәгать) | | |
| Беренче сентябрь көне ничек узуы турында сөйли белү.<br>Дәрес әзерли торган эш урыны турында сөйли белү.<br>Көндәлек режимны сөйли белү.<br>Уку хезмәтенә карашы буенча укучыга бәя бирә белү.<br>Әңгәмәдәшеңнең ничәнче сыйныфта укуын, нинди өй эшләрен әзерләвен, дәрестә нәрсәләр эшләвен сорый белү.<br>Китапханәчедән кирәкле китап турында белешмә ала белү. | Яңа уку елы башланды. Без укытучыларны котладык. <...><br>Мин тәртип яратам. Минем эш урыны чиста.<br><br>Алёша иртән сәгать 7 дә тора.<br>Оля яхшы укый. Ул — тырыш укучы.<br><br>Дәрестә нишләдең? Мин мисалны дөрес эшләдем, мәсьәләне дөрес чишмәдем.<br><br>Сездә кошлар турында китаплар бармы? | чәчәк бәйләме, бәйрәмчә, эчтәлек, сәнгатьле, тәрҗемә ит, уйла, куш, ал, тапкырла, бүл, башлана, быел, былтыр, тәртип, эш урыны, һәрвакыт, кирәкле, игътибарлы(сыз), көндәлек, контроль эш, күчерә, чишә, гаепле, үкенә, оныта, күңелле |
| **Кошлар һәм хайваннар дөньясында** (20 сәгать) | | |
| Кошлар, аларны саклау турында әдәби әсәрләр аша сөйләшү.<br><br>Хайваннар турында сорый һәм белешмә бирә белү. Аларны тасвирлый белү. | Кыш көне кошларга бик салкын. <...> Марат кошларга таш ата. Ул — начар малай. <...><br>Аның төсе ... . Ул кыш көне ... . Ул ... ашый. | буе, авырлыгы, энә, энәле, ташый, ташбака, ярыша, ояла, үкенә, урлый, кызгылт, чикләвек, каты, җәнлек, бөҗәкләр, арыслан, юлбарыс, таш, үлә |
| **Кышкы уеннар** (25 сәгать) | | |
| Спорт төрләрен әйтә, үзеңнең нинди спорт төрен яратканыңны, балалар яратып уйный торган төрле уеннарда катнашуың турында әйтә, уенга чакыра, уенның вакытын әйтә белү. | Мин хоккей яратам. Мин хоккей уйныйм. Әйдә, хоккей уйныйбыз. Уен сәгать 10 да башлана. | рәхәт, шатлана, мактый, шуа белә (белми), елга буе, туңган, коткарды, батыр, җитез, очрашабыз, куркак, туңа, бата, суза, уен |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| Уенга барырга кирәклегенә инандыра, бару-бармауның сәбәбен әйтә белү.<br><br>Укылган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү, геройларга бәя бирү. | Әйдә, урамга чыгабыз. Урамда күңелле, рәхәт, саф һава. Синең чанаң бармы? Минем чанам юк. Миңа чана бир әле. Мин бармыйм, чөнки дәрес әзерлим.<br>Коля — батыр малай, чөнки ул бабайга ярдәм итте. | |
| **Минем дусларым** (25 сәгать) | | |
| Үзеңнең дустың турында сөйли белү.<br><br>Кечкенә хикәяләрнең эчтәлеген сөйли, геройларга бәя бирә белү. | Минем дустым бар. Аның исеме — Айсылу. Без аның белән бергә укыйбыз. Без бергә мәктәпкә йөрибез.<br>Ул тырыш, әдәпле, тыйнак. | бергә, тыйнак, ярар, соң, әйбер, бик, ямьле, гел, бал, әйтмәде, кемдер, сылтау, сыйныфташ, күрше, бию түгәрәге, таныштык, көтә, табышмак, башмаклар, алып кайта, кия, сала |
| **Дүрт аяклы дусларыбыз** (15 сәгать) | | |
| Дүрт аяклы дусларыбызның кыяфәтләре, гадәтләре турында сөйли белү.<br>Аларга карата үз мөнәсәбәтеңне белдерә белү. | Песиемнең койрыгы йомшак, колаклары кечкенә, күзләре яшел. <...><br><br>Мин этемне бик яратам, аш бирәм, аның белән урамга чыгам. | хуҗа, эзли, маңгай, адаша, коткара, кача, ябыша |
| **Яз килә** (20 сәгать) | | |
| Язгы табигать турында сөйли белү.<br><br>8 нче Март бәйрәме белән котлый белү.<br>Яз бәйрәме — Карга боткасы турында сөйли белү. | Ямьле, күңелле яз җитте. Елгада боз китә. Җылы яктан кошлар кайта. Без кошларга оя ясыйбыз. Көннәр — озын, төннәр кыска була.<br>Кадерле әнием! Сине бәйрәм белән котлыйм.<br>Яз көне матур бәйрәм була. Ул — Карга боткасы. <...> | җылы як, боз китә, кайта, озын, кыска, тамчы тама, кояш җылыта, кар эри, күгәрчен, сыерчык, оя ясый, Карга боткасы, өйдән өйгә, буенда, алып килә |
| **Татарстан** (20 сәгать) | | |
| Татарстанның дәүләт символларын әйтә белү.<br><br>Казан шәһәре турында сөйли белү. | Татарстанның нинди дәүләт символлары бар? Дәүләт флагында нинди төсләр бар?<br>Казан — бик матур, зур шәһәр. Миңа Казан ошады. Кремльдә Кол Шәриф мәчете бар. <...> | Дәүләт гербы, Дәүләт флагы, Дәүләт гимны, дәүләт теле, манара, Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы, ерак (түгел), шәһәре, язучы |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| Татарстан шәһәрләре турында сөйләшү.<br><br>Балалар шагыйрьләре, язучыларының исемнәрен, нәрсә язганын әйтә белү. | Татарстанда нинди шәһәрләр бар? Алабуга Казаннан еракмы?<br>Бари Рәхмәт — шагыйрь. Ул шигырьләр яза. Дәрҗия Аппакова — язучы. Ул хикәяләр яза. | |
| **Матур җәй җитә** (25 сәгать) | | |
| Җәй көне кая бару турында сөйләшү.<br><br>Бакчада җәйге хезмәт турында сөйли белү. | Син җәй көне кая барасың? Мин җәй көне авылга барам. <...><br>Бакчада эшлим. | ял итә, ярдәм итә, чүп утый, җыя |

Башлангыч этапта өйрәнү өчен тәкъдим ителгән шагыйрьләр һәм язучылар: **Г. Тукай, М. Җәлил, А. Алиш, Ф. Кәрим, Х. Гарданов, Б. Рәхмәт, Ә. Бикчәнтәева, Р. Миңнуллин, Г. Лотфи, Җ. Тәрҗеманов, Ш. Галиев, Җ. Дәрзаман, Р. Вәлиева, Д. Аппакова, Р. Корбан, Н. Мадьяров, Г. Рәхим, Х. Халиков, И. Туктар, М. Газизов, Р. Батулла, Р. Мингалим, Г. Бәширов, Л. Толстой, В. Осеева**.

## Грамматик минимум

1. Татар телендәге хәреф-аваз системасына анализ бирә белү.
2. Исемнәрнең килеш кушымчаларын сөйләмдә дөрес куллану.
3. Исемнәрне күплек санда тартым белән төрләндерү.
4. *Маратның китабы* төзелмәсен сөйләмдә куллану.
5. Кушма, парлы исемнәрнең мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә куллану.
6. *Кадәр, соң* бәйлекләре белән таныштыру.
7. Чагыштыру, артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатларның мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә куллану.
8. *Монда, анда* күрсәтү алмашлыкларын сөйләмдә куллану.
9. *Мин, син, ул* зат алмашлыкларының иялек, юнәлеш, урын-вакыт килешләрендә төрләнешен сөйләмдә куллану.
10. Билгесез үткән заман хикәя фигыльне III зат берлек санда сөйләмдә куллану.
11. Татар һәм рус телләрендә җөмләдәге сүз тәртибе белән таныштыру.
12. *Иртәгә эшлим* конструкциясе белән таныштыру.

## Орфоэпик һәм орфографик минимум

1. Сүз басымы. Аны дөрес куя белүгә ирешү, рус сүзләре белән чагыштырып күрсәтү. Басымлы иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес уку һәм матур язу күнекмәләре булдыру. Басымның үзенчәлекле очракларын белү.

2. Җөмлә ахырында нокта, сорау яки өндәү билгеләрен куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү.

3. Орфоэпик һәм орфографик яктан сөйләмне оештыру эшен тирәнәйтү.

## 5 нче СЫЙНЫФ (168 сәгать)

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Без мәктәптә** (20 сәгать) | | |
| Дәресләр расписаниесен, нинди дәресләр әзерләү яки әзерләмәүнең сәбәбен әйтә белү.<br>Уку-язу әсбапларын тәртиптә тоту турында киңәш бирә белү.<br>Китапханәгә барырга чакыра һәм нинди китап кирәклеге турында әйтә белү. | Күнегү эшлим, мисал, мәсьәлә чишәм.<br>Битләрне пычратма, ташлама, ертма, бөкләмә.<br>Наил, әйдә, китапханәгә барабыз. Миңа табигать турында китап кирәк. | әдәбият, ташлый, чирек, кәеф, язма эш, шакмаклы, сызыклы, әзерләнә, сүздә тору, сыйныф җитәкчесе, быел, узган ел, югалта, мөстәкыйль эш, вакытында эшләргә, борчыла, ерта, пычрата, ачык, ябык, куша, ала, тапкырлый, бүлә, төшеп калган, маҗаралы |
| **Мин — өйдә булышчы** (20 сәгать) | | |
| Өйдә эшләгән эшләрне әйтә, сорый, куша белү.<br>Эш эшләргә риза булуыңны яки булмавыңны белдерү.<br>Кибеткә барырга куша, нәрсә алырга икәнен әйтә, сорый белү.<br>Өйдәге хезмәттә катнашуга карап, кешеләргә бәя бирә белү.<br>Өйдәге эшләрне эшләргә киңәш бирә һәм яхшы эшләгән өчен мактый белү.<br>Вакытны дөрес әйтә белү, сөйләмдә куллану. | Мин идән юам. Син идән юасыңмы? Идән ю әле. Ярый, мин идән юам. Юк, юмыйм. Мин риза (түгел).<br>Нәрсә алырга? Ипи, сөт ал.<br>Айдар — эшчән малай, чөнки ул әнисенә булыша.<br>Әнигә булышырга, идән юарга кирәк. Син булдыргансың, яхшы эшләгәнсең. Син эшчән, тырыш, ярдәмчел.<br>Дәресләр сәгать ничәдә башлана? Тугызынчы яртыда. <...> | тузан суырта, тузан сөртә, кер үтүкли, чүп чыгара, себерә, ашарга әзерли, әрчи, тыңлаучан, ихтирамлы, җитез, көчле, мактанчык (түгел), алдаша, булышчы, алдашмый, минем фикеремчә, минем уйлавымча, мич, ярдәмчел, иртә тора, алтын, тимер, иртәнге, кичке, көндезге, булдыра, шәп |
| **Бергә эшлә, бергә аша** (24 сәгать) | | |
| Өй эшләрендә үзеңә булышырга, ярдәм итәргә сорый, нәрсә эшләргә кирәклеген әйтә белү. | Аня, миңа булыш әле. Миңа савыт-саба юарга ярдәм ит әле. | ярдәм, чакыра, бозыла, йокы, минемчә, синеңчә, билгеле, әлбәттә, беренчедән, икенчедән, |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| Кереш сүзләр кулланып, геройлар адымына карата үз фикереңне әйтә белү. | Минемчә, Аня дөрес эшләмәде, чөнки ... . Минем уйлавымча, Супермалай эшчән түгел, чөнки ... . | мич, он, көртлек, чишмә, утын кисә, утын яра, маҗаралы, кар көри, су алып кайта |
| **Ничек эндәшсәң, шулай җавап бирерләр** (14 сәгать) | | |
| Үзеңә, иптәшеңә ярдәм итүне итагатьле сорый, ярдәмеңне тәкъдим итә белү.<br>Өлкән кешегә сорау белән мөрәҗәгать итә белү.<br>Телефоннан сөйләшү этикеты. | Миңа булыш әле. Гали, көрәк алып чык әле. Зинһар, миңа ярдәм ит әле. Сиңа булышырга кирәкме?<br>Әйтегезче (әйтегез әле), киемнәр кибете кайда? Гафу итегез, тукталыш кайда?<br>Оляны телефонга чакырырга мөмкинме? Миңа Оля кирәк иде. | тиз-тиз, башкалар, пычрак, тәмле сүз, тәмле телле, оялды, чакырыгыз, гафу үтенә, тупас, ялгыз, мактана, гаепле, очрады, тукталыш, кагыйдә, ашыга, гафу ит, шалтырата |
| **Минем туган көнем** (18 сәгать) | | |
| Туган көнгә чакыру яза белү.<br>Бәйрәм табынын әзерләү турында сөйләшү.<br>Нинди ризыклар яратканыңны яки яратмаганыңны әйтә белү.<br>Табын янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре.<br>Туган көн уеннары турында сөйләшә белү. | Оля, мин сине туган көнгә чакырам. Туган көн кич сәгать 6 да башлана, безнең адрес: ... .<br>Нәрсә пешерәбез, кемнәрне чакырабыз? Табында нәрсәләр була? Төрле салатлар ... . <...><br>Син нинди ризыклар яратасың ( яратмыйсың)?<br>Сөйләшергә, ашыгырга ярамый. <...><br>Нинди уеннар уйныйбыз? Син нинди тизәйткечләр, табышмаклар беләсең? | чакыру кәгазе, татар халык ашлары исемнәре, туңдырма, пылау, токмачлы аш, коймак, ак май, беренчегә, күрше, авыз чапылдату, ашыга, пәрәмәч, вак бәлеш, күтәрә, кыстый, тук, яңа гына, кулын суза |
| **Минем дустым бар** (15 сәгать) | | |
| Дустың турында сөйли белү.<br>Дусларның аралашуы турында сөйли белү.<br>Дустыңны уенга чакыра белү. | Минем дустым — Катя. Ул матур җырлый, яхшы ... . <…><br>Дуслар бергә дәрес әзерлиләр, ... .<br>Оля, әйдә, уйнарга чыгабыз. <…> | шатлык, шаян, иптәш, ярдәмчел, киңәш, менә, төшә, үлгән, ишегалды, юлдаш, һәркем, һәрбер, кызгана |
| **Дүрт аяклы дусларыбыз** (15 сәгать) | | |
| Дүрт аяклы дусларыбызның токымнары, кыяфәтләре, гадәтләре турында сөйли белү. | Минем этем (песием) бар. Ул йонлач, ... . <...> Ул тәпиен бирә, ... . <...> | йорт эте, ау эте, сакчы эт, йонлач, ут яна, тәпи, юаш, тугры, сөяк, күсе, тычкан, ягымлы, тәпиен суза |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Без спорт яратабыз** (15 сәгать) | | |
| Тән әгъзаларының исемнәрен, табибка кайсы җирең авыртуын әйтә белү. Җәйге, кышкы спорт төрләрен аера, үзеңнең нинди спорт төрен яратканыңны әйтә белү. | Минем тешем сызлый, башым авырта. <...><br><br>Мин чаңгы шуарга яратам. <...> | спорт төрләре, салкын тия, башым әйләнә, сызлый, күз табибы, теш табибы |
| **Без Татарстанда яшибез** (15 сәгать) | | |
| Татарстанның табигате: елгалар, үсемлекләр, җәнлекләрнең исемнәрен әйтә белү.<br>Сабантуй турында һәм милли уеннарны әйтә, Сабантуйга афиша яза белү. | Татарстан — зур, бай республика. Татарстанда зур елгалар ... .<br><br>Сабантуйда ат чабышы, ... . <...> | Кама, Идел, Агыйдел, Зәй, Ык, озынлыгы, киңлеге, бодай, арыш, карабодай, борчак, чөгендер, көнбагыш, тары, бәхәсләшә, кебек, ризык, татарча көрәш, капчык белән сугышу, чүлмәк вату, капчык киеп йөгерү |
| **Светофор — минем дустым** (12 сәгать) | | |
| Юл йөрү кагыйдәләрен сөйли белү. | Юл янында уйнарга, ... ярамый. Кызыл ут яна, ашыкма. Юлда йөгерергә ярамый. | җәяүле, уң як, сул як, урам аша, ашыга, тукталыш, юл бирә |

## Грамматик минимум

1. Боерык фигыльнең барлыкта һәм юклыкта (II зат) төрләнешен сөйләмдә куллану.
2. Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше.
3. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше.
4. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнеше белән танышу.
5. Фигыльнең инфинитив формасын сөйләмдә куллану.
6. Фигыльнең инфинитив формасын модаль сүзләр *(кирәк, кирәкми, ярый, ярамый)* белән сөйләмдә куллану.
7. *Эшләргә телим* конструкциясен сөйләмдә куллану.
8. Сыйфат дәрәҗәләре белән таныштыру, аларны сөйләмдә куллану.
9. *Өчен, шикелле* бәйлекләрен сөйләмдә куллану.
10. Кереш сүзләрне *(минемчә, синеңчә, билгеле, әлбәттә, беренчедән, минем фикеремчә)* сөйләмдә куллану.
11. Татар телендә аффиксларның кушылу тәртибе белән таныштыру.

12. -*лык/-лек; -даш/-дәш, -таш/-тәш* исем ясагыч кушымчалары белән таныштыру.

13. Зат алмашлыкларын урын-вакыт килешендә сөйләмдә куллану.

14. Тартым һәм килеш белән төрләнгән уртаклык һәм ялгызлык исемнәренең берлек һәм күплек сан кушымчаларын аера белү.

15. Җөмләдә ия белән хәбәрне дөрес куллана белергә өйрәтү.

16. *Мин, син, ул* зат алмашлыкларының төшем килешендә сөйләмдә кулланылышы.

## 6 нчы СЫЙНЫФ (168 сәгать)

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Яңа уку елы котлы булсын!** (30 сәгать) | | |
| Китапның якын дус, киңәшче икәнен аңлата, китап укырга киңәш бирә белү.<br>Каюм Насыйри турында кыскача мәгълүмат бирә белү.<br>Китапханәгә язылу өчен, анкета тутыра белү, китапханәдән үзеңә кирәкле китапны сорый белү.<br>Китап басу тарихы турында кыскача белешмә бирә белү.<br>Уку-язу әсбапларына сак караш турында сөйләшү. | Китап укырга кирәк. Китап — якын дус, чөнки ... .<br>К.Насыйри — тарихчы, ... . <...><br>Ул — дәреслекләр авторы. Минем исем-фамилиям ... . <...><br>Беренче китапны ... . <...><br>Көндәлекне саклап тота, ... . | киңәшче, төрле киңәш, фән, бәхәс, бәхәсләшә, таныша, тарихчы, тәрҗемәче, телче, галим, аңлатмалы сүзлек, искә төшерә, теләсә кая ыргытмый, ертмый, шапшак, ташлый, чүп-чар, бөкли, мактана, иске, саклап тота, яшь, турында, зарлана, шундый, майлы, буялды, ачыла, ябыла, почмак, китап басучы, кульязма, һәйкәл |
| **Мин — зур ярдәмче** (28 сәгать) | | |
| Нинди эшләр эшләргә яратканыңны, эшләргә теләгәнеңне, нәрсәләр эшләгәнеңне әйтә белү.<br>Эшне эшләргә инандыра, ышандыра белү.<br>Кереш сүзләрне кулланып, үз фикереңне раслый белү.<br>Образларга бәя бирә белү. | Мин гөлләргә су сибәргә яратам. Мин бакчада эшләргә телим.<br>Әбигә булышырга кирәк, чөнки ул ... .<br>Минемчә, Әхмәт ялкау түгел, ул ... . | шаян, кызганычка каршы, бәхеткә каршы, киресенчә, әлбәттә, ялгышты, мактый, күңелсез, бөтен, үзем, бергә, башы, уртасы, ахры, терелә, югалтты, тапты, балалар бакчасы, пәке, гадел |
| **Минем дустым** (25 сәгать) | | |
| «Дус нинди була? Ни өчен дуслашалар? Дуслар бергә нишлиләр? Минем дустым — ул нинди?» проблемалары буенча сөйләшү.<br>Укыган хикәянең эчтәлеген сөйли белү. | Дус гадел, ... . Дуслар белән күңелле, дуслар берберсенә булышалар, ... .<br>Дуслар бергә дәрес әзерлиләр, ... .<br>Минем дустым намуслы, ... . | авыр хәл, гадел, алдаша, намуслы, бер-берсенә, рәхәт, шатланды, вата, шәфкатьле, һәр, игътибарлы, үпкәли |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Туган көн — күңелле бәйрәм** (13 сәгать) | | |
| Туган көнгә чакыру турында киңәшләшү.<br><br>Төрле рецептларны сөйли белү.<br>Кунакларны сыйлау, кыстау формалары. | Туган көннең вакытын, урынын алдан әйтергә кирәк.<br>«Зебра» тортын пешерү өчен, ... .<br>Табынга утырыгыз, әйдә, чәй эчәбез, торт алыгыз. <...> | тәмләткечләр, тавык (сарык) ите, җитешегез, пешерү өчен, шикәр комы, каймак, дөге, корт |
| **Туган җирем — Татарстан** (30 сәгать) | | |
| Татарстанда яшәүче милләтләр, үзеңнең милләтеңне, нинди телдә сөйләшүеңне әйтә белү.<br>Татарстанның табигате турында сөйли белү.<br>Казан шәһәре турында мәгълүмат бирә белү.<br><br>Татар сәнгать вәкилләренең исемнәрен әйтә белү.<br><br><br><br>Язучыларның, шагыйрьләрнең, җырчыларның исемнәрен әйтә белү. Театрга чакыра, караган спектакль турында фикереңне әйтә белү. | Татарстанда татарлар, руслар, чувашлар яшиләр. Мин русча, татарча сөйләшә беләм. Вася нинди телдә сөйләшә?<br><br>Казан — зур, матур шәһәр. <…> Казанда Г. Тукай музее бар. <…><br>Сара Садыйкова — танылган татар композиторы. Салават Фәтхетдинов — күренекле җырчы.<br>Мин «Авыл эте Акбай» спектаклен карадым. Пьеса авторы — Туфан Миңнуллин. Спектакль миңа бик ошады. | дәүләт, күпмилләтле, дәүләт телләре, яңалыклар, ил, балалар, яшьләр театры, курчак театры, күренекле, рәссам, кызыксына, гармун, курай, танылган, атаклы, Татар дәүләт академия театры, дөнья, иҗат итә, галим |
| **Дүрт аяклы дусларыбыз** (22 сәгать) | | |
| Дүрт аяклы дусларыбызның токымнары, кыяфәтләре, гадәтләре турында сөйләшә белү. Дүрт аяклы дусларыбызның хуҗаларына карашы турында сөйләшү. | Минем этем бар. Ул йонлач, ... . <...><br><br><br>Тәмлетамак — иркә, ялкау мәче. Ул хуҗасын яратмый, тыңламый. <...> | улый, кочаклый, иркә, хәйлә, ялганлый, тәпиен бирә, токым, койрыгын болгый, сагына, күрешә, сөяк, оя, тук, онык, сабыр, күчтәнәч |
| **Сәламәт тәндә — сәламәт акыл** (20 сәгать) | | |
| Сәламәт булу өчен, нинди кагыйдәләр үтәргә кирәген сөйли белү.<br><br>Төрле спорт түгәрәкләренә йөрү турында сөйләшә белү. | Көндәлек режимны сакларга, чыныгырга, тәртипле яшәргә кирәк. <...><br><br>Син нинди спорт түгәрәгенә йөрисең? Мин айкидо түгәрәгенә йөрим. | саклый, чыныга, тәмәке тарту, зарарлы, еш, яланаяк, җиңде, җиңелде, акыл хезмәте, тәҗрибә |

## Грамматик минимум

1. Туры сөйләм белән таныштыру.
2. Тартымлы исемнәрне килешләр белән төрләндерү, текстта таный белү.
3. Хәл фигыльнең *-гач/-гәч, -кач/-кәч* формасы белән таныштыру.
4. *Бәхеткә каршы, кызганычка каршы, киресенчә* кереш сүзләрен сөйләмдә куллану.
5. Шарт фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше.
6. Билгесез үткән заман хикәя фигыльне сөйләмдә куллану.
7. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнеше.
8. Җөмләнең баш кисәкләре: ия һәм хәбәр. Алар арасында сызык куелу очраклары белән таныштыру.
9. *Барыйм әле* төзелмәсе белән таныштыру.
10. Чакыру кәгазе яза белү.
11. *Барасы килә, эчәсе килми* төзелмәләре белән таныштыру.
12. Җыю, микъдар, тәртип саннарының кулланылышын кабатлау.
13. Боерык фигыльне барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләндерү.
14. *Минем барасым килә (килми)* төзелмәсен куллану.

# 7 нче СЫЙНЫФ (168 сәгать)

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Яхшы уку җиңелме?** (30 сәгать) | | |
| Яңа уку елындагы яңалыклар, сыйныфташларының ничек укуы, нинди билгеләр алу, өй эшен ничек эшләү, дәрестә ничек катнашу турында сөйләшү.<br>Уку-язу әсбапларын тәртиптә тоту турында сөйләшү.<br>Яхшы уку серләре турында сөйләшү.<br>Яхшы уку өчен, нинди сыйфатлар кирәклеге турында сөйләшү. | Быел безнең яңа сыйныф җитәкчесе. <...> Безгә яңа фәннәр керә. <...><br>Самат китапны саклап тотмый, теләсә кая ыргыта. <...><br>Яхшы уку өчен, көн дә дәрес әзерләргә кирәк, ... . <...><br>Яхшы уку өчен, тырыш, игътибарлы булырга кирәк. <...> | сыйныф җитәкчесе, фән, имтихан, тикшерә, аеруча, искиткеч, ярыйсы, тутыра, уртача, фән, уку әсбаплары, пышылдый, тырыша, күзге, онытырга, күчерергә, игътибарлы булырга, чирек азагы, үз сүзендә торучан, белем, надан, эшмәкәр |
| **Мин һәм минем яшьтәшләрем** (20 сәгать) | | |
| Яшьтәшләреңнең тышкы кыяфәтен, характер сыйфатларын әйтә белү.<br>Матур киенү серләре турында сөйләшү.<br>Алдашу — иң яман гадәт, хатаңны тану — батырлык икәне турында сөйләшү. | Минем дустым озын буйлы, ... . <...> Ул оялчан, ... . <...><br>Мин дискотекага кызыл күлмәк киям. Кызыл төс ... .<br>Алдашсаң, үзең кыен хәлдә каласың. Бер алдашсаң, сиңа ышанмыйлар ... . <...> .Үз хатаңны тану, гафу үтенү өчен, ихтыяр көче кирәк. | ябык, таза, киң җилкәле, кыска буйлы, бөдрә, җирән, тупас, оялчан, киң күңелле, усал, булдыклы, җитез, заманча, каеш, өрәңә, игътибар үзәге, аксыл-көрән, тынычлык, универсаль, алдакчы, алдашты, ялганчы, кызарды, кайгы, тынычландырды, үкенде, оялды, гафу үтенде, начарлык, сукыр, нур, җиңелде, җиңде, бата, коткарды, ихтыяр көче |
| **Безнең ял** (23 сәгать) | | |
| Үз фикереңне белдерә белү. | Мин риза. Мин дә шулай уйлыйм. <...> | риза (түгел), фикерем башка, файдалы (сыз), файдаланырга, теләгәнчә, иректә, кайберәүләр, көнозын, |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| Буш вакыт — ул нинди вакыт, аны ничек файдаланырга?<br>Буш вакытны файдалы, файдасыз үткәрү, яраткан шөгылең турында сөйли белү.<br>Кесә телефоны, ноутбук, плеер куллану, компьютерга бәйлелек турында сөйләшү. | Буш вакыт ул — ... . <...><br>Минем буш вакытым аз, чөнки ... . Әгәр буш вакыт булса, ... . <...><br>Минем яраткан шөгылем — ... . <...><br>Кесә телефоныннан күп сөйләшү сәламәтлеккә зыянлы. <...> Мин компьютерда төрле уеннар уйныйм. <...> | озын, төкерә, сыра, бушка гомер үткәрә, тик йөрү, кул чабу, тамаша, шөгыль, тапшырулар, кесә телефоны, зыян, бернәттән, бәйлелек, акча туздыру, җитди, мавыгу |
| **Өлкәннәр һәм без** (20 сәгать) | | |
| Өлкәннәр һәм кечкенәләрнең гаиләдә үзара мөнәсәбәте турында сөйләшү. Өлкәннәргә үзеңнең кая барырга, нишләргә теләгәнеңне әйтә белү, өлкәннәрдән рөхсәт сорый белү.<br>Дусларыңа үз-үзеңне әдәпле тоту буенча киңәш бирә белү. | Кечкенәләр үзләренчә яшәргә тели, ә өлкәннәр моңа риза түгел. <...><br>Әни, миңа дискотекага барырга рөхсәт ит әле.<br>Өлкәннәрне хөрмәт итәргә кирәк. <...><br>Әниләрне борчырга ярамый. <...> | үзләренчә, өлкәннәр, кечкенәләр, мөнәсәбәт, ялгышу, хаклы, һәркем, кыланыш, рәнҗи, ояла, модада түгел, шәфкать, борчу, борчыла, хөрмәт итү |
| **Дүрт аяклы дусларыбыз** (15 сәгать) | | |
| Дүрт аяклы дусларыбызга карата мәрхәмәтлелек турында сөйләшү.<br>Бөек Ватан сугышында этләрнең батырлыклары турында сөйли белү. | Дүрт аяклы дустым сагына белә ... .<br>Дүрт аяклы дусларга мәрхәмәтле булырга кирәк, чөнки ... .<br>Этләр яхшы элемтәче булганнар, кырларны миналардан чистартканнар. <...> | тугры, таный, Бөек Ватан сугышы, батырлык, элемтәче, хәбәр, яралы, алып чыга |
| **Әдәбият-сәнгать дөньясында** (25 сәгать) | | |
| Татар җырчылары, композиторлары турында сөйли белү.<br>Татар сәнгать тарихына кергән һәм бүгенге көндә иҗат итүче сәнгать эшлеклеләре турында кыскача белешмә бирә белү.<br>Татар рәссамнары, сәнгать эшлеклеләре турында сөйли белү. | С.Сәйдәшев — беренче профессиональ композитор. <...> С.Садыйкова — танылган композитор. <...> Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова — татар халкының яраткан җырчылары. <...><br>Харис Якупов — портрет һәм пейзаж остасы. <...><br>Ирек Мөхәммәдев — бөтен дөньяга танылган биюче. | остаз, мәңге, сердәш, ышанычлы, тәҗрибәле, фикердәш, моңлы, төбәк, хыяллана, ягымлы, сынлы сәнгать, рәсем сәнгате, гашыйк, күргәзмә, пейзаж остасы, халыкара фестиваль, ия була, төп партия, атказанган артист, талантлы шәхес, оста |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Без Татарстанда яшибез** (20 сәгать) | | |
| Татарстанның территориясе, аның географик урыны, климаты, файдалы казылмалары. | Татарстан Республикасының территориясе ... . Ул Башкортстан, ... , Оренбург өлкәләре белән чикләшә. Республикада ... климат. Республика ... кебек файдалы казылмаларга бай. | затлы, мул, уңдырышлы туфрак, кара алтын, ком, газлаштыру, файдалы казылмалар |
| Казанның тарихи урыннары турында сөйли белү. | Казан тарихи истәлекләргә бик бай. <...> | Тарихи үзәк, борынгы, вакыйга, югары уку йортлары |
| **Юл йөрү кагыйдәләре (15 сәг.)** | | |
| «Яшь юл хәрәкәте инспекторы» эшчәнлеге, «Имин тәгәрмәч» республика конкурсы турында сөйләшү. | Мин — яшь юл хәрәкәте инспекторы. Хәзер рейдка чыгам. <…> «Имин тәгәрмәч» республика конкурсында Тимур җиңде. Ул беренче урын алды. <…> | тәгәрмәч, юл хәрәкәте, имин, штраф салу, тизлек, эшчәнлек, җәрәхәтләнде, туктатты, исерек, «ашыгыч ярдәм» машинасы |

## Грамматик минимум

1. Хәл фигыльнең 4 нче формасы *(-ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче)* белән таныштыру; *-ып, -еп, -п; -гач/-гәч, -кач/-кәч* формаларын сөйләмдә куллану.
2. Исем фигыль формасы белән таныштыру.
3. Кушма, парлы, тезмә исемнәрнең ясалышы, аларны сөйләмдә куллану.
4. Сыйфат фигыльнең хәзерге һәм үткән заман формалары белән таныштыру.
5. Рәвеш төркемчәләре белән таныштыру, сөйләмдә куллану.
6. Синоним һәм антоним сүзләрне сөйләмдә куллану.
7. Тезүче *(һәм, да/дә, әмма, яки)* һәм ияртүче ***(әгәр, шуңа күрә)*** теркәгечләрне сөйләмдә куллану.
8. Тәрҗемә аша кисәкчәләрнең семантик мәгънәләре белән таныштыру *(да, дә, та, тә; гына/генә, иң, бит, инде)*.
9. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә өйрәтү.
10. Җыючы *(һәм, да/дә, та/тә, ни...ни)*, каршы куючы *(ләкин, ә, әмма)*, бүлүче *(я, яки)* теркәгечләре белән җөмләләр төзү күнекмәләрен системалаштыру.

## 8 нче СЫЙНЫФ (136 сәгать)

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Күп укыган күп белер** (28 сәгать) | | |
| «Яхшы уку җиңелме?» проблемасы буенча сөйләшү.<br><br>«Яхшы уку һәм яхшы яшәү» проблемасы буенча фикер алышу.<br>Интернет аша үз белемеңне күтәрү турында сөйләшү.<br><br>Татарстанның Милли китапханәсе турында сөйли белү. | Яхшы уку өчен, үзеңә күп таләпләр куярга кирәк: дәрестә игътибарлы булырга, көн дә өй эшен эшләргә кирәк. Өй эшен күчерергә ярамый. <...><br>Яхшы яшәү өчен, яхшы уку кирәкме? Минемчә, ... .<br>Син Интернет белән дусмы?<br>Рефератка материалны Интернеттан алдым.<br>Татарстанның Милли китапханәсе Казанда урнашкан. <...> | өлгерә, соңга кала, җитешә, иртәрәк, арый, сүз бирә, сүзендә тора, оныта, вакытында, борчыла, тантаналы, узды, бүлек, ялгышты, хәзинә, компьютерлаштырылган, аралаша, килешү, аңлатмалы сүзлек, мәдрәсә, фарсы, гарәп, эзли, аралашу, чит ил, килешү, сирәк басма, атаклы |
| **Мин һәм минем яшьтәшләрем** (30 сәгать) | | |
| Яшьтәшләрең белән аралашу кагыйдәләре, дуслашу серләре, нинди кызлар һәм малайлар ошавы турында сөйләшү.<br><br>Яшүсмерләрнең үзара мөнәсәбәтләрендә алдашу кебек күренешләргә үз карашыңны белдерә белү.<br>Яшүсмерләрнең файдалы хезмәттә катнашуы, гаилә бюджетына үз өлешләрен кертә алулары турында сөйләшү.<br><br>Укучылар арасындагы яшь талантлар турында әйтә белү. | Яшьтәшләреңне хөрмәт итәргә, аларга игътибарлы булырга, ... кирәк. Миңа эшчән кызлар, тәмәке тартмый торган малайлар ошый. <...>.<br>Алдашу — начар гадәт.<br><br>Җәй көне мин хезмәт бригадасында (хезмәт лагеренда) эшләдем ... .<br>«Яшелләндерүчеләр» бригадасында хезмәт хакы зур булды ... . Көнлек хезмәт хакы ... сум иде. Мин гаилә бюджетына үз өлешемне кертергә тырышам ... .<br>Сыйныфташым Оля бик матур җырлый. <…> | аралашу, алдашу, һичшиксез, кызара, читләшә, гаеп эзли, ялгышын тану, үпкәләшү, мөнәсәбәт, ялгыз, дәрәҗә, иркен, сөйкемле, тыйнак, ягымлы, сыра, тәмәке, батыр, горур, үз-үзеннән артык канәгать, ант итү, кызыксыну, адым, терелә, көнозын, гарьләнү, елак, көнләшү, чая, кызыксыну, серле, төп роль, хезмәт бригадасы, яшелләндерү, чистарту, хезмәт хакы, гаилә бюджеты, үз өлешем |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Буш вакытымны мин ничек үткәрәм?** (22 сәгать) | | |
| «Егетлек» проблемасы буенча сөйләшү.<br><br>Яраткан музыкаң турында фикер алышу.<br><br>Виртуаль аралашуның төрле ысуллары турында сөйләшү. | Нәрсә ул егетлек? Буш вакытны ничек үткәрү егетлек була ала?<br>Миңа күбрәк татарча рэп ошый. Мин «Иттифак» төркеме белән кызыксынам. <...><br>Минем Интернетта үз сайтым, электрон адресым бар. Мин Интернеттан файдалы мәгълүматлар алам. <...> | тәртипсезлек, өлгерлек, егетлек, тупаслык, эшсезлек, башкаручы, иң, әйләнә-тирә, уртак тел табу, эчке дөнья, уенкөлке, игътибар үзәге, читләшү |
| **Табигать һәм кеше** (18 сәгать) | | |
| Табигатькә сак караш турында сөйләшү.<br><br>Табигать серләре, табигатьтәге кызыклы күренешләр турында мәгълүмат бирә белү.<br>«Мин чисталык яратам», «Кошларга ярдәм» акцияләрендә катнашу турында сөйләшү. | Ял иткән урынны чиста калдырырга кирәк, чөнки ... .<br>Чишмәләр — изге урын, ял итү урыны, шуңа күрә ... .<br><br>Оксана «Яшел планета» конкурсында беренче урынны алды, чөнки ул ... . | көрәшү, ягулык, учак ягу, чүп-чар, пычрату, чишмә, Җир шары, дым саклау, катнаша, җиңә |
| **Без Татарстанда яшибез** (20 сәгать) | | |
| Татарстанның урыны, климаты, мәйданы, табигый байлыклары турында сөйли белү.<br>Казан шәһәрендәге үзгәрешләр турында сөйли белү.<br><br>Бүгенге Казан, архитектура истәлекләре, яңа ял итү урыннары. | Татарстан Европаның көнчыгышына урнашкан.<br>Миңа Казан метросы ошады. <…> Казанда яңа спорт корылмалары төзелде ... .<br>Сиңа Бауман һәм Санкт-Петербург урамнарының кайсы күбрәк ошый? Без аквапаркта ял итәргә яратабыз, чөнки ... . | Европа, көнчыгыш, чикләшә, мәйдан, төньяк, көньяк, күмер, бакыр, балчык, бик, кайсы, оештырыла, истәлек, корылмалары |
| **Татарстанның күренекле әдипләре** (18 сәгать) | | |
| Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Абдулла Алиш турында сөйли белү. Аларның шигырьләрен яттан сөйләү.<br>Абдулла Алиш, Галимҗан Ибраһимов турында белешмә бирә белү, әсәрләренең эчтәлеген кыскача сөйләү. | Габдулла Тукай 1886 нчы елда мулла гаиләсендә туа. <…><br><br>Муса Җәлил — Советлар Союзы Герое. <…><br>Абдулла Алиш — Җәлилнең дусты. | мәдрәсә, ятим, үги әби, иҗат итә, ачы язмыш, яланаяк, асрарга, олаучы, гаҗәпләнде, кала, күрше авыл, мәкалә, әдәби әсәр, Бөек Ватан сугышы, әсирлек, тоткынлык, көрәш, төрмә, фашизмга каршы, легионерлар, үлемсез, мәңгелек, дан |

## Грамматик минимум

1. Сыйфат фигыльнең барлыкта һәм юклыкта заман формалары белән танышу.

2. Хәл фигыльнең 4 формасын да сөйләмдә куллану.

3. Хикәя фигыльнең тәмамланмаган үткән заман, күптән үткән заман, кабатлаулы үткән заман формаларын текстта таный белү.

4. Фигыльнең йөкләтү, уртаклык юнәлешләре белән таныштыру.

5. Теләк фигыльне *(-ыйм/-им, -ыйк/-ик)*, теләк белдерүнең башка формаларын сөйләмдә куллану.

6. Боерык фигыльнең III затта төрләнеше.

7. Бәйлек һәм бәйлек сүзләрне сөйләмдә куллану.

8. Фразеологик берәмлек төшенчәсе белән таныштыру.

9. Билгеләү, билгесезлек, юклык, күрсәтү, тартым алмашлыкларының сөйләмдә еш кулланыла торган очраклары белән танышу.

10. Сан төркемчәләрен гомумиләштереп кабатлау.

11. Сөйләмдәге актив ымлыклар белән танышу.

12. Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне сөйләмдә куллану.

13. Аналитик фигыльләр *(килеп җитте, укып бетерде)* белән танышу.

14. Атау җөмләләрне сөйләмдә танып белү.

## 9 нчы СЫЙНЫФ (136 сәгать)

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Без Татарстанда яшибез** (16 сәгать) | | |
| Татарстанның икътисади (экономик) хәле, аның чит илләр белән бәйләнешләре турында әйтә белү.<br>Татар музыка сәнгате тарихы турында сөйли белү.<br>Александр Ключарёв, София Гобәйдуллина, Салих Сәйдәшев турында белешмә бирә белү.<br>Татар театр сәнгате барлыкка килү турында белешмә бирә белү. | Татарстан күп илләр белән икътисади (экономик) бәйләнешләргә керә, шартнамәләр төзи.<br>Заһидулла Яруллин — беренче кыллы оркестр төзегән халык музыканты. <…><br>София Гобәйдуллина — Швеция Короле Сәнгать академиясе әгъзасы. <…><br>1906 нчы елның 22 нче декабре — татар театры туган көн. <…> | халыкара, хокук, мөңьеллык, манара, шәхес, борынгы, башкара, шартнамә, сайлаучылар, сайлыйлар, мөстәкыйль, кыллы оркестр, моң, сәнгать осталары, нигез салучы, сәхнә әсәрләре, сәнгать эшлеклесе, яңгырап тора, гадәт, уен коралы, сәләт, мәдәни үзәк, драма театры, дәртле, нурлы, гасыр, тамаша, тамашачы, оештыручы |
| **Китап — киңәшчем, дустым минем** (18 сәгать) | | |
| Китаплар, китапханәләрнең тормышыбыздагы роле турында сөйли белү.<br>Китаплар дөньясыннан кызыклы фактлар турында сөйләшү.<br>Белем алу һәм тормышта үз урыныңны табу проблемасы турында сөйләшү. | Нинди китаплар, газета-журналлар укуны файдалы, ә нindiләрен вакыт әрәм итү дип саныйсыз? Өегездә нинди китаплар бар? Сез кызыксынган китаплар киләчәктә сайлаячак һөнәрегез белән бәйлеме?<br>Китап уку кирәкме, әллә Интернет та җитәме? Мин ... турында укырга яратам. Уңышлы бизнес оештыру өчен, беренче чиратта белемле булу кирәк, ... . <…> | хөрмәт, татар халкы, аерым, инглиз, немец, кытай, гарәп, француз, горурлык, фәнни, гасыр, сирәк, атаклы, дөнья, системалы, билгеле, күрсәтә, ишетелә, чит тел, киңәш, югары белем, ялчы, мәгарә, коткара, уңышлы, белемле |
| **Һөнәр сайлау** (22 сәгать) | | |
| Үз гаилә әгъзаларының профессияләре турында сөйләшү. | Минем әтием заводта токарь булып эшли. Ул үз эшен бик ярата. <…> | һөнәри училище, хастаханә, дәвалау, нәтиҗә, чир, кадрлар бүлеге, |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| Төрле профессияләргә хас сыйфатлар турында фикер алышу.<br><br>Үзеңә ошаган профессияне яклый белү. | Укытучы булу өчен, балаларны яратырга, үз фәнеңне яхшы белергә кирәк. <…><br>Миңа пешекче профессиясе ошый, чөнки мин пешерергә яратам.<br>Мин гөлләр үстерергә яратам. <…><br>Мин буйый беләм. <…> | нефтьче, бораулаучы, эш стажы, пешекче, трамвай йөртүче, эшче профессияләре исемнәре, җаваплы, белемле, төгәл, гариза, кабул итү |
| **Аралашу әдәбе** (30 сәгать) | | |
| Дуслыкны саклый белү серләре турында сөйләшү.<br><br>Яшүсмерләрнең бәйрәмнәре турында сөйләшү.<br><br>Ярыймы, ярамыймы? Кайчан, нәрсә турында сөйләшергә мөмкин? Сөйләшү әдәбе турында фикер алышу. | Дустыңа дөресен әйтү авыр, ләкин ... .<br>Син башкаларны тәнкыйтьләргә яратасыңмы? Нинди сыйфатларың үзеңә ошамый?<br>Гашыйклар көнен кайда, ничек бәйрәм итәләр? Гашыйклар көнендә сез ничек аралашасыз?<br>Аралаша белү — үзе бер осталык. Кешене тыңлый белмәү — начар гадәт. Кайбер кешеләр гел үзләре генә сөйлиләр. <…> | күрмәмешкә салышу, әшәке, битараф, тату яшәү, ялкаулана, сугышу, сүгенү, күз йому, гашыйклар, хат, ялагайлык, әңгәмәдәш, читкә борылу, чын күңелдән сөйләшү, елмаеп сөйләшү, чыннан да |
| **Буш вакыт** (25 сәгать) | | |
| Спорт төрләре, Татарстанның атаклы спортчылары, төрле спорт түгәрәкләренә йөрү турында сөйләшү.<br>Дусларыңны спорт белән шөгыльләнергә кирәклегенә инандыру.<br>Ял көнен планлаштыру.<br><br>Караган фильм, андагы геройлар турында фикер алышу.<br>Минем виртуаль дөньям. Компьютер уеннары, программалар төзү, онлайн режимында аралашу, төрле сайтларга теркәлү, компьютер белән мавыгу турында сөйләшү | Миңа төрле спорт төрләре ошый: ... . Мин волейбол белән шөгыльләнәм. Спорттагы кумирым — ... .<br>Спорт белән шөгыльләнергә кирәк, чөнки ... . <...><br>Әйдә, ял көне дискотекага барабыз. Бүген яңа музыка була.<br>Миңа бу фильм бик ошады, чөнки … . Төп рольне ... .<br>Мин үз сайтымны булдырдым.<br>Дустым белән онлайн режимында аралашам. <…><br>Компьютер уеннары белән мавыгу зыянлымы? | шөгыльләнә, түгәрәк, бәлки, күргәзмә, кумир, осталык, бәяләнде, тамашачылар, алкышлар, теләү, күренекле, атаклы, танылган, виртуаль дөнья, сайтка теркәлү, мавыгу, зарарлы |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Табигать һәм кеше** (15 сәгать) | | |
| «Кеше һәм табигать» проблемалары буенча сөйләшү. | Мин — табигать баласы. Табигать бай, ләкин аны сакларга кирәк. Янгын булмасын өчен, ... . | казылма байлыклар, зарарлы матдәләр, агулана, янгын, киләчәк, буын, үсемлек, кими, куркыныч |
| **Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый** (10 сәгать) | | |
| Бөек Ватан сугышы турында белешмә бирә белү. 9 нчы Май — Җиңү көне. Рейхстагка җиңү байрагын элүчеләр, Бөек Ватан сугышында катнашкан өлкән буын — ветераннар турында сөйләшү. | Бөек Ватан сугышы 1941 нче елда башлана. <…> Бөек Ватан сугышында безнең әтинең бабасы катнашкан. <…> Рейхстагка байрак элүчеләр арасында татар егетләре дә була. <…> | Бөек Ватан сугышы, дәвам итә, яралылар, һөҗүм итә, көчле сугыш, очучы, чигенә, буын, элүче, байрак, өлкән, әсирлек |

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә (5—9 нчы сыйныфлар) уку һәм сөйләшү өчен тәкъдим ителгән әсәрләрнең авторлары: **Дәрдемәнд, Г. Тукай, М. Җәлил, Һ. Такташ, С. Хәким, Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов, И. Гази, М. Мәһдиев, Ф. Яруллин, Т. Миңнуллин, В. Нуриев, Ф. Шәфигуллин, М. Галиев, Р. Миңнуллин, Ш. Галиев, Л. Лерон, Н. Мадьяров, З. Гомәрова, Р. Вәлиев, Р. Вәлиева, Н. Гыйматдинова, М. Газизов, В. Осеева, Ю. Ермолаев**.

## Грамматик минимум

1. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләренең исемнәрен әйтә, сорау куя, аера белү.
2. Гади һәм кушма җөмләләрне аера белергә өйрәтү.
3. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрне сөйләмдә куллана белү күнекмәләрен булдыру.
4. Җыючы, каршы куючы, бүлүче теркәгечле кушма җөмләләрне сөйләмдә куллану.
5. Иярчен хәл җөмләләрнең *иярчен вакыт җөмлә, урын җөмлә, рәвеш җөмлә, күләм җөмлә, максат җөмлә, шарт җөмлә, сәбәп җөмлә, кире җөмләләре* белән таныштыру һәм аларны сөйләмдә урынлы куллануга ирешү.
6. Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес кую һәм аларны тиешле интонация белән әйтү.

# 10 нчы СЫЙНЫФ (102 сәгать)

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Белем һәм тормыш** (15 сәгать) | | |
| Киләчәккә минем сайлаган юлым. Теләк һәм мөмкинлекләр.<br><br>Казан дәүләт университеты турында сөйли белү.<br>Казан университетының Н. И. Лобачевский исемендәге китапханәсе турында сөйли белү.<br>Төрле телләр өйрәнү кирәклеге турында сөйләшү.<br>Чит илләрдәге татарлар тормышы турында сөйләшү. | Син кем булырга телисең? Ни өчен алай уйлыйсың? ... булу өчен, нинди булырга кирәк? Син бүген киләчәккә ничек әзерләнәсең?<br>Казан дәүләт университеты 1804 нче елда ачыла.<br>Н.И.Лобачевский исемендәге китапханә Казан университетында урнашкан. <…><br>Татар телен һәм чит телләр белү бик кирәк, чөнки ... .<br>«Телләр белгән — илләр гизгән» дигәнне ничек аңлыйсың? Конкурент шәхес булу өчен, телләр белү кирәкме? Синең тормышыңда татар теле нинди роль уйный? Син кайсы телне күбрәк беләсең, ни өчен? | туры килә, мөмкинлек, әрәм итү, сердәш, кыйммәтле, мәгънәсез, хәсрәт, ялгызлык, алыштырыла, иркен сөйләшә, гарәп әлифбасы, латин графикасы, төбәк, таралган, зыялы, хөрмәт яулый, түзә, көчле ихтыярлы, фәлсәфи |
| **Шушы яктан , шушы туфрактан без...** (15 сәгать) | | |
| Татар халкы тарихы турында белешмә бирә белү. Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары турында сөйләшү.<br><br>Татарстанның сынлы сәнгате турында кыскача сөйли белү. | Борынгы Болгар дәүләте Идел буенда барлыкка килә ... . Сөембикә манарасы — Казанның күренекле архитектура истәлеге.<br>Б. Урманче, С. Ахун, Х.Якупов,Л.Фәттахов — Татарстанның атаклы рәссамнары. | Болгар, Биләр, төрки, кабилә, сәүдә, буйсынган, күн, дан казанган, мөселман, ислам дине, гөнаһ, мунча, бәхәсләшкәннәр, тәңкә, оста, ханбикә, бәет, патша, патшабикә, тәкъдим итә, таләп итә, кияүгә чыга, меңьеллык, Казансу, Спас, истәлек, кирпеч, |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| Яшәгән төбәгеңдә сине борчыган проблемалар турында сөйләшү. Татарстанда яшьләр хәрәкәте, яшьләрнең төрле акцияләрдә катнашуы. | Син яшәгән төбәктә сине нәрсә борчый? Киләчәк авылын, шәһәрен ничек күз алдына китерәсең? Волонтёр — эш сөючән, намуслы, аралашучан, ярдәмчел. «Парклар маршы»нда, «Чиста шәһәр», «Чыршы» акцияләрендә катнашу һәркемнең дә бурычы, чөнки ... . | манара, шәхес, мәчет, хан, шәкерт, һәлак була, яндырыла, илче, эш сөючән, намуслы, аралашучан, катнаша, яшьләр хәрәкәте, сынлы сәнгать, бурыч, теләк, сәләтле |
| **Зарарлы гадәтләрдән сакланыгыз!** (22 сәгать) | | |
| Сәламәтлек — үзе бер бәхет.<br><br>Зарарлы гадәтләр, алардан ничек котылырга?<br><br>Модага ияреп киенү һәм сәламәтлек. | Сәламәт булу өчен, беренче чиратта ... . Дөрес туклану организм өчен бик файдалы, чөнки ... . Зарарлы гадәтләрне булдырмас өчен, ... . Синеңчә ничек, тәмәке тарту, сыра эчү — заманча яшәүме? Кызлар — булачак әниләр, шуның өчен ... . Ничек уйлыйсың, кием сайлаганда, иң беренче чиратта нәрсәгә игътибар итәбез? Киемне матур булып күренү өчен генә кияләрме, әллә ... . Еш авыру сәбәпләренең берсе — дөрес киенмәү. | яхшырта, спорт төрләре, акыл хезмәте, физик хезмәт, туклану, кыздырылган, агулы матдә, күңел болгану, баш әйләнү, һуштан язу, яман шеш, бозыла, шәраб, сыра, аракы, исерткеч эчемлекләр, томалый, агулана, татып карау, кешелексезлек, кәсеп, кулланучы, керем, мәҗбүри, укол кадау, күнегә, хәлсезләнә, начарлык, дару кабул итү |
| **Дустың булмаса эзлә, тапсаң сакла** (15 сәгать) | | |
| Дустым, аның уңай һәм тискәре сыйфатлары, яхшы һәм начар гадәтләре, дус була белү, дуслар белән аралашу серләре. | Минем дустым эшчән, ләкин ул бик тиз кызып китүчән ... . Әгәр дустыңның кайгысы бар икән, аны уртаклаша бел, ярдәм ит ... . Исәп-хисапка, алдашуга корылган дуслык ... . Бер-береңне хөрмәт итүгә, саклауга корылган дуслык ... . | тәэсир итә, хыянәт итә, буйсына, уртаклаша, тиз кызып китүчән, битараф, ялагай, үзсүзле, тугры, яхшылык, мәкерле, исәп-хисап, мавыгу, теркәлү, горурлык, кочаклашу, үбешү, дорфа, вак җанлы, ризалык, бозыклык, сафлык, хис, гадәтсез |
| **Саф хисләр, беренче хисләр...** (25 сәгать) | | |
| Кызлар-малайлар дуслыгы, үзара аралашу әдәбе буенча сөйләшү. | Без Оля белән 8 нче сыйныфта дуслаштык. <...> Миңа ... кызлар ошый. | горур, горурлык, җитди, тәмле телле, сүгенү, әшәке сүз, аз сүзле, шаян, минминлек, мәхәббәт, саклау, |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
| --- | --- | --- |
| Саф хисләр, беренче хисләр, аларга сак караш турында сөйләшү.<br>Бергә ял итү турында сөйләшү. | Ул миңа бик ошый. Мин аның ... сыйфатларын яратам.<br>Син дискотекага барырга телисеңме?<br>Минем театрга барасым килә. | танышу, ышану, ышанмау, гашыйк булу, берберенә тартылу |
| **Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый** (15 сәгать) | | |
| Бөек Ватан сугышы чорында Татарстан кызлары һәм улларының батырлыгы. | Муса Җәлилнең шигырь дәфтәрләрен алып кайтучы кеше — Андре Тиммерманс. <...><br>Муса Җәлил биографиясен Константин Симонов, Гази Кашшаф, Рафаэль Мостафин өйрәнгән. <...><br>Г. Гафиятуллин батырлыгы. <...> | мәгънә, тентү, хыянәтче, үкенечле, сер эзләүче, көрәштәш, тоткынлык, васыять, каһарманлык, күмелгән, илчелек, мәрмәр, үлем ярасы, ыргытты, каплады, капланды, тәүлек |

# 11 нче СЫЙНЫФ (102 сәгать)

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| **Алда юллар, кайсын сайларга?** (26 сәгать) | | |
| Югары уку йортлары һәм без сайлаган һөнәрләр. | Татарстандагы югары уку йортлары: ... . Мин киләчәктә югары уку йортында укырга телим, чөнки ... . | киләчәк, уку йорты, заман, киләчәк мәктәбе, борчый, икътисади, шәфкатьле, җаваплы |
| Бүгенге икътисади тормыштагы яңа һөнәрләр. | Социологлар, логистлар, промоутерлар — алар кемнәр? | |
| Бүгенге мәктәптә мине борчыган проблемалар. | Безнең заманга аттестатлы кешеләр түгел, белемле кешеләр кирәк. <...> Бүгенге мәктәптә мине күп мәсьәләләр борчый. <...> Киләчәк мәктәбен мин шулай күз алдына китерәм: ... . <...> | |
| Без сайлаган профессияләр, аларга куелган таләпләр. | Минемчә, табиб иң беренче чиратта шәфкатьле, җаваплы булырга тиеш. | |
| **Шушы яктан , шушы туфрактан без...** (12 сәгать) | | |
| Татарстанның яңа икътисади үсеш дәрәҗәсе, дөньякүләм аренада бүгенге урыны. | Татарстанның икътисади (экономик) куәте белән бүген бик күп чит илләр кызыксына. <...><br>2013 нче ел бөтендөнья спорт тарихында Татарстанның яңа урынын билгеләде. <...> | үсеш дәрәҗәсе, икътисади куәте, дөньякүләм урыны, өлеш, бөтендөнья тарихы, ярышлар, спорт корылмалары |
| Татарстанның бөтендөнья спорт үсешенә керткән өлеше, Казандагы яңа спорт корылмалары турында сөйләшү. | Су спорт сараенда синхрон йөзү буенча ярышлар була. <...> | |
| **Спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше** (14 сәгать) | | |
| Спорт төрләре, дөньякүләм танылган спортчылар, Татарстанның атаклы спортчылары. | Россия спорты тарихында 2013—2014 нче ел вакыйгалары ... . Биеклек королевасы Елена Исин- | биеклек, дөнья рекорды, шартлар, чаралар, Олимпия уеннары, һәркем, беркем, һичкайчан |

| Коммуникатив максат | Якынча сөйләм үрнәкләре | Сүзләр һәм сүзтезмәләр |
|---|---|---|
| <br><br><br><br><br>Шәһәребездә, авылыбызда спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар. Алар нинди?<br><br><br>Сәламәт яшәү рәвеше турында сөйләшү. | баева ... . Татарстан спортчысы Гөлнара Сәмитова-Галкина Пекинда Олимпия уеннарында яңа дөнья рекорды куйды.<br>Спорт секцияләренә һәркем йөри аламы? Яшьләр спорт белән шөгыльләнсен өчен, нинди шартлар һәм чаралар оештырыр идең?<br>Сәламәт яшәү һәркемнең үз кулында. Моның өчен сәламәт яшәү кагыйдәләрен белергә кирәк. <...> | |
| **Гаилә һәм балалар** (25 сәгать) | | |
| Балаларны ярату, саклау, укыту — ата-ананың балалар алдындагы бурычы. Ятим балалар проблемасы.<br><br><br>Балаларның ата-аналар каршындагы бурычы, өлкәннәргә мөнәсәбәт проблемалары. | Балалар йортында ятимнәр саны кимеми, чөнки ... . Һ. Такташның «Ана — бөек исем, Нәрсә җитә ана булуга!» фикере белән мин килешәм, чөнки ... .<br>Өлкәннәрне ихтирам итү, алар турында кайгырту, аларга булышу — яшьләрнең бурычы. | ятим, ятимлек, балалар йорты, меценатлык хәрәкәте, рәхмәтле, бүлешү, картлык, кайгырту, рәнҗү, үкенү, искә алу, оныту, беренчел |
| **Беренче хисләр , гаилә кору** (25 сәгать) | | |
| Дуслык мәхәббәткә әверелә аламы?<br>Дуслыкта, мәхәббәттә кызларның һәм егетләрнең роле. Мәхәббәт һәм байлык.<br><br><br><br>Без гаилә корырга әзерме?<br>Катнаш гаиләләр, аларның киләчәге? | Дуслык һәм мәхәббәтнең нигезе — ... . Бер-береңне ярату ул — ... . Минем яраткан кызым (егетем) ул — ... . Минем яраткан егетем (кызым) миңа игътибарлы, минем өчен борчыла ... .<br>Чын ир-ат булсаң, ... .<br>Гаилә кору — зур җаваплылык, чөнки ... . Гаилә кору өчен, ... . Үпкәләшүнең төп сәбәпләре ... . Катнаш гаилә озын гомерле була алмый, чөнки ... . | көнләшү, аптырау, ялкынланып яну, шелтәләү, чын ярату, ошата, кызыксындыра, коткара, яра, тормыш рәхәтләкләре, көнләшә, көнчел, җаваплылык, катнаш гаилә, үпкәләшү |

Урта гомуми белем бирү мәктәбендә (10—11 нче сыйныфлар) уку һәм сөйләшү өчен тәкъдим ителгән әсәрләрнең авторлары:

**Ф. Әмирхан, Г. Камал, Һ. Такташ, Ә. Еники, Г. Ахунов, Г. Кутуй, Г. Әпсәләмов, Х. Туфан, И. Юзеев, М. Мәһдиев, Г. Сабитов, Т. Миңнуллин, Р. Миңнуллин, Г. Гыйльман, Н. Гыйматдинова, Р. Гаташ, Р. Фәйзуллин, Ф. Яруллин, Р. Батулла, З. Мансуров, М. Насыйбуллин, А. Гыймадиев, Л. Шагыйрьҗан, Ф. Сафин, З. Хәким, М. Маликова, Ә. Гаффар, Л. Ихсанова.**

# РУС ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШҮЧЕ БАЛАЛАРНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕННӘН БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘРЕН ТИКШЕРҮ ТӨРЛӘРЕ

## Башлангыч сыйныфлар

| № | Эш төрләре | Сыйныфлар | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **1** | **2** | **3** | **4** |
| 1. | Тыңлап аңлау | Сүзләр, сүзтезмәләр | 0,1—0,2 минут | 0,2—0,4 минут | 0,3—0,5 минут |
| 2. | Диалогик сөйләм | 3 реплика | 4 реплика | 5 реплика | 6 реплика |
| 3. | Монологик сөйләм | 4 фраза | 5 фраза | 6 фраза | 7 фраза |
| 4. | Һәр тема буенча аралаша белү күнекмәләрен ситуатив күнегү-ләр аша тикшерү | 2 | 2 | 3 | 4 |
| 5. | Уку | 15—25 сүз | 25—35 сүз | 35—45 сүз | 45—55 сүз |
| 6. | Язу: | | | | |
| | күчереп язу (гади җөмлә) | 1—2 җөмлә | 3—4 җөмлә | 4—5 җөмлә | 5—6 җөмлә |
| | сүзлек диктанты | | 5—6 сүз | 7—8 сүз | 8—9 сүз |
| | сочинение (өйрәнү характерында) | | | 4—5 җөмлә | 5—6 җөмлә |

## 5 — 9 нчы сыйныфлар

| № | Эш төрләре | Сыйныфлар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **5** | **6** | **7** | **8** | **9** |
| 1. | Тыңлап аңлау | 0,5—0,7 минут | 0,8—0,9 минут | 1 минут | 1,2 минут | 1,5 минут |
| 2. | Диалогик сөйләм | 5—6 реплика | 6—7 реплика | 7—8 реплика | 9—10 реплика | 11—12 реплика |
| 3. | Монологик сөйләм | 7—8 фраза | 8—10 фраза | 8—10 фраза | 10—12 фраза | 10—12 фраза |
| 4. | Һәр тема буенча аралаша белү күнекмәләрен ситуатив күнегүләр аша тикшерү | 4 | 4 | 4 | 4 | 5 |

| № | Эш төрләре | Сыйныфлар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 5. | Уку | 55—60 сүз | 60—70 сүз | 70—80 сүз | 80—90 сүз | 90—95 сүз |
| 6. | Язу: | | | | | |
| | сүзлек диктанты | 8—10 сүз | 10—15 сүз | 15—18 сүз | 18—22 сүз | 22—25 сүз |
| | сочинение | 5—7 җөмлә | 7—8 җөмлә | 8—9 җөмлә | 9—10 җөмлә | 10—12 җөмлә |

## 10—11 нче сыйныфлар

| № | Эш төрләре | Сыйныфлар | |
|---|---|---|---|
| | | 10 | 11 |
| 1. | Тыңлап аңлау | 1,5—2,0 минут | 2—2,5 минут |
| 2. | Диалогик сөйләм | 11—12 реплика | 13—14 реплика |
| 3. | Монологик сөйләм | 10—12 фраза | 12—14 фраза |
| 4. | Һәр тема буенча аралаша белү күнекмәләрен ситуатив күнегүләр аша тикшерү | 5 | 5 |
| 5. | Уку | 95—100 сүз | 95—100 сүз |
| 6. | Язу: | | |
| | сүзлек диктанты | 25—27 сүз | 28—30 сүз |
| | сочинение | 12—15 җөмлә | 13—15 җөмлә |

### Укучыларның сөйләм күнекмәләрен бәяләүгә аңлатма

Рус телле балаларга татар теле укытуның төп максаты — Татарстан Республикасында дәүләт телләренең берсе дип игълан ителгән татар телендә иркен сөйләшә ала торган билингваль шәхесләр формалаштыру. Билгеле булганча, социолингвистика фәне кешеләрне координатив (ана телендә һәм өйрәнә торган башка телдә хатасыз аралашу), субординатив (ана телендә хатасыз, өйрәнә торган телдә хаталар җибәрү фараз ителә) һәм катнаш типларга (ике телдә дә аралашуда хаталар булу фаразлана) аерып карый. Программа авторлары рус телле балаларга татар телен өйрәтүнең төп максатын субординатив типтагы шәхесләр формалаштыруда күрәләр. Ягъни рус телле балалар язма һәм телдән аралашу процессында хаталар җибәрсәләр дә, аларның программада күрсәтелгән тематика буенча татар телендә сөйләшә-аралаша белүләре таләп ителә.

Чит телләр укыту методикасында белемнәрне тикшерү өчен, «коммуникативно-достаточный уровень — аралашу өчен җитәрлек дәрәҗә; коммуникативно-недостаточный уровень — аралашу өчен җитәрлек булмаган дәрәҗә» төшенчәләре бар (В.П.Беспалько). Әгәр үзләштерү дәрәҗәсе 0,7 коэффициентыннан югары булса, аралашу өчен җитәрлек дәрәҗә дип санала һәм укучыга «4», «5»ле билгеләре куела; әгәр үзләштерү дәрәҗәсе 0,7 коэффициентыннан түбән булса, аралашу өчен

җитәрлек булмаган дәрәҗә дип санала һәм укучыга «3», «2»ле билгеләре куела. Ягъни үзләштерү коэффициенты 0,7 булса — «3»ле, 0,8—0,9 булса — «4»ле, 0,9 — 1 булса — «5»ле билгеләре куела.

Үзләштерү коэффициенты түбәндәге формула белән исәпләнә:

Үк = а : р, монда Үк — үзләштерү коэффициенты, а — дөрес үтәлгән биремнәр саны, р — барлык биремнәр саны.

Әйтик, сүзлек диктанты 20 сүздән тора, ди. Укучы 5 хата җибәрә. Аның үзләштерү коэффициенты болай исәпләнә: 15 : 20 = 7,5. Укучы «4»ле билгесе ала.

Әйтик, укучыларның сөйләшә алуын тикшерү өчен, 5 ситуатив күнегү бирелде, ди. Укучы 4 күнегүдә сөйләм максатын дөрес аңлап аралаша алуын күрсәтте. Аның үзләштерү дәрәҗәсе коэффициенты болай була: 4 : 5 = 0,8. Укучы «4»ле билгесе ала.

Әйтергә кирәк, чиреклек, еллык билгеләр нинди дә булса грамматик категорияне үзләштерү дәрәҗәсе белән генә билгеләнми, ә программада күрсәтелгән темалар буенча укучыларның диалогик, монологик сөйләмгә чыгу дәрәҗәләре белән билгеләнә.

## РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАРГА ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУ ПРОЦЕССЫН КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ НИГЕЗЕНДӘ ОЕШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Рус телле балаларны татар сөйләменә өйрәтү процессы **коммуникатив технология** нигезендә цикллылыкка корылган. **Цикл — текстны укып, аның эчтәлеген диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр саны**. Бу сан даими түгел. Ул текстның лингвистик яктан катлаулылыгына, текстның күләменә, укучыларның фикерләү сәләтләре дәрәҗәсенә бәйле.

Методик әдәбиятта күрсәтелгәнчә, текстны өйрәнү өч этаптан тора: **текст алды, текст** һәм **текстан соңгы этаплар**. Беренче этапта укучылар текстны лингвистик яктан кабул итәргә әзерләнергә тиешләр. Дәрес тибы буенча бу дәресләр **лексик күнекмәләр формалаштыру дәресләре** (ЛКФ) һәм **грамматик күнекмәләр формалаштыру дәресләре** (ГКФ) дип аталалар. Әгәр тел өйрәтү процессын тел һәм әдәбият дәресләренә бүлү укыту планына кертелгән икән, без аларны татар теле дәресләре, ягъни татар теленең лексикасына, грамматикасына өйрәтү дәресләре дип атарбыз. Укучылар, текстны лингвистик яктан беркадәр кабул итәргә әзерләнгәч, текстның үзен укырга күчәргә мөмкин. Бу дәресләрдә, нигездә, турыдан-туры текстны уку, текст буенча эш күнегүләре өстенлек итә. Шуңа күрә аны уку дәресләре дип атарга мөмкин. Дәрес тибы ягыннан алар **лексик-грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресләре** (ЛГКК) була. Бу тип дәрес тә, текстның катлаулылыгына карап, бер яки берничә дәрес булырга мөмкин. Мондый дәресләрдә алда өйрәнелгән лексика һәм грамматика турыдан-туры текстта кабатлана, төрле бәйләнешләргә керә, ягъни лингвистик материални сөйләмдә куллану камилләшә.

Тексттан соңгы этапта текст эчтәлеге һәм аңа салынган әхлакый проблема буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу дәресләре оештырыла. Дәрес типлары да **диалогик-монологик сөйләм дәресләре** дип атала. Бу дәресләрдә тексттагы лексик-грамматик материал сөйләмдә мөстәкыйль кулланылу дәрәҗәсенә җиткерелә, укучылар материал эчтәлеге буенча спонтан сөйләм этабына чыгалар. Аңлашылганча, тел өйрәтү процессында татар теле һәм әдәбият дәресләре үзара шартлы бәйләнештә булалар. Циклда әдәби әсәрне өйрәнү өчен бирелгән сәгатьләр санына татар теле дәресләре саны да, әдәбият дәресләре саны да керә. Шуны искәртергә кирәк: «Мәгариф» турында Федераль Законның 55 нче маддәсенең 4 нче пункты нигезендә укытучы программадагы сәгатьләр санын, укучыларның мөмкинлегенә карап, эш программасына үзгәртеп кертә ала.